МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ
ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ

**«ЗАБАВА»**

Детский сад комбинированного вида «106»
г. Набережные Челны

РАСЛЫЙМ
«Кызыклы уен» 106 нчы балалар бакчасы»
МАМББ мөдире :
Гимадеева З.Д.
«26»__08__2022 ел

Каралды һәм кабул ителде
педагогик советта
«26»__08__2022 ел
беркетмә № 1

# «Кызыклы уен» 106 нчы катнаш балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе 6 нчы мәктәпкәчә әзерлек (6-7 яшь) төркеменең 2022-2023 нче уку елына эш программасы.

Төзүче:
[illegible]

Яр Чаллы
2022ел

**Эчтәлек**


| | |
|---|---|
| **Кереш** | |
| **I Максатчан бүлек** | |
| 1. Аңлатма язуы | |
| 2.Эш программасының максаты һәм бурычлары | |
| 3. Программаны формалаштыруның принциплары | |
| 4. Төркем турында белешмә | |
| 5. Балаларның яшь үзенчәлекләре | |
| **II Эчтәлекле бүлек** | |
| 1 Белем бирү эшчәнлегенең тематикасы | |
| 2 .Белем бирү өлкәләренең эчтәлеге | |
| 3 Әти-әниләр белән эш<br>4 Мәктәп белән эш | |
| **III Оештыру бүлеге** | |
| 1.Материаль техник тәэмин итү | |
| 2.Программа-методик тәэмин итү | |
| 3.Знче мәктәпкәчә әзерлек төркеменең көн тәртибе | |
| 4.Знче мәктәпкәчә әзерлек төркемендә оешкан белем бирү эшчәнлеген оештыру | |
| 5. Әдәбият исемлеге | |
| **IV Кушымта** | |
| | |

## Кереш.

“Об образовании в Российской Федерации” Федераль кануныna нигезләнеп, Россиядә мәктәпкәчә белем бирү гомуми белем бирүнең беренче дәрәҗәдәге статусын алды. Белем бирү программаларын тормышка ашырганда мәктәпкәчә белем бирү ФДББС “Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» (Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации № 1155 от 17 октября 2013 года), нигезендә җайга салына. Аның төп бурычы- шартлар тудыру, шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру. Программаны төзегәндә белем бирү үсешендә хͤезерге заман халыкара тенденцияләр исәпкә алынды:

- балада әйләнә-тирәгә яңа караш формалаштыру;
- практикада белем бирүнең төп юнәлешләрен (экологик, экономик, социаль) тормышка ашыру;
- эшчәнлектә балаларның шәхси тәҗрибәләрен (көнкүреш, культура, социаль, әхлакый) актив куллану;
- балалар инициативасын, белем омтылышын, мөстәкыйльлеген үстерү;
- белем бирү процессын нәтиҗәле итү өчен төрле эшчәнлекне берләштерү (интегральләштерү);
- балаларның уенга, куркынычсызлыкка, уңайлы әйләнә-тирәгә хокукын саклау;

-сыйфатлы белем алуга мөмкинлек тудыру; - балаларны социумга актив кертү.

Төп гомуми белем бирү программасы МАМББУ № 106 "Кызыклы уен" мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе базасында якынча төп гомуми белем бирү программасын ("Туганнан мәктәпкә кадәр" редакциясе. Н.Е. Вераксы, Т. С. Комарова, Э.М.Дорофеева — М.: МОЗАИКА СИНТЕЗ, 2021 ел.) эшләнгән.

Төп гомуми белем бирү программасы бала шәхесен яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, социаль-коммуникатив, танып белү, сөйләм үстерү, нәфасәти һәм физик үсешен тәэмин итә.

**Федераль дәрәҗәдә:**

- Федеральный закон от 29.12.2012 № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (с изменениями от 13.07.2021г.).

-Федеральный закон от 03.08.2018 г. №317 –ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации».

- Федеральный государственный образовательный стандарт дошкольного образования (Утвержден приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 октября 2013 г. N 1155).

- Комментарии к ФГОС дошкольного образования Минобрнауки России Департамента общего образования от 28 февраля 2014 года № 08-249.

- Приказ Министерства просвещения РФ от 31 июля 2020 г. № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования».

- Постановление Правительства РФ от 15 сентября 2020г. №1441 «Об утверждении Правил оказания платных образовательных услуг».

- СП 2.4.3648 – 20 «Санитарно – эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденный Постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020 №28 об утверждении санитарных правил. Зарегистрирован в Министерстве юстиции РФ от 18.12.2020 №61573.

- Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.01.2021 №2 «Об утверждении санитарных правил и норм СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или)безвредности для человека факторов среды, обитания» (вместе с СанПиН 1.2.3685-21 «Санитарные правила и нормы..»).

- Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 27.10.2020 г. №32 «Об утверждении санитарно-эпидемиологических правил и норм СанПиН 2.3/2.4.3590-20» Санитарно-эпидиомологические требования к организации общественного питания населения.

- Санитарно-эпидемиологические правила СП 3.1/2.4.3598-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации работы образовательных организаций и других объектов социально инфраструктуры для детей и молодежи в условиях распространения новой коронавирусной инфекции (COVID-19)», утвержденный постановлением Главного государственного санитарного врача РФ от 30.06.2020 №16, с изменениями от 24.03.2021 г. (Постановление Главного государственного санитарного врача РФ №10 «О внесение изменений).

- Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013г № 68-ЗРТ (принят Государственным Советом 28.06.2013 г).

- Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других Языках в Республики Татарстан» (изменения и дополнения от 28.07.2004 г № 44-ЗРТ; от 12.06.2014 г № 53-ЗРТ).

**Җирле дәрәҗәдә:**

- Устав муниципального автономного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад комбинированного вида № 106 «Забава»;
- Основная образовательная программа дошкольного образования муниципального автономного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад комбинированного вида № 106 «Забава»;
- Рабочая программа воспитания муниципального автономного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад комбинированного вида № 106 «Забава».

# I. Максатчан бүлек
## 1.Аңлатма язуы

Бүген җәмгыятьтә катлаулы социаль-экономик процесслар бара, белем бирүнең кыйммәтләре һәм максаты тамырдан үзгәрә. Балаларга белем бирүнең бөтен өлкәләрендә дә актив, иҗади, үзен үзгәртергә әзер торучы шәхес тәрбияләү таныла. Балаларның шәхси һәм социаль мөнәсәбәт позициясен күздә тотып, аларны мәктәпкә әзерләүдән күчү, мәктәпкәчә белем бирү нәтиҗәләренең күзаллавын үзгәртергә булыша. Нәтиҗәлелек: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда кызыксынучанлык, активлык, мөстәкыйльлек сыйфатларын формалаштыра; ялгышларны уңышсызлыкларны җиңеп чыгарга әзерлек, яңа белем алырга, стандарт булмаган ситуацияләрдән чыгу юлын эзләргә омтылыш тудыра; үзе сайлаган эшкә җаваплылык, командада эшли белү, үзенә, башкаларга, җәмгыятькә, әйләнә-тирәгә ихтирамлы караш, кайгыртучнлык тәрбияли. Болар барысы да баланы мәктәпкә әзерләп кенә калмый, ә хәзерге җәмгыятьтә уңышлы мөстәкыйль эшләү өчен нигез булып тора. Билгеле, мондый нәтиҗәләргә ирешү өлкәннәрнең фикер йөртүендәге үзгәртеп корулар белән бәйле, педагоглар һәм ата-аналар үзгәртеп коруда үзләре башлап йөрергә тиеш. Шунлыктан, Программа педагог-бала- ата-ана мөнәсәбәтенә ориетлаштырылган.
Вакыт илебезнең мәгариф учреждениеләре эшенең яңа иҗтимагый-икътисади шартларда алып барылыу мәктәпкәчә мәгарифне заман таләпләренә туры китереп үзгәртүне, дәүләт һәм гаиләнең бала тәрбияләүдәге ролен яңа прогрессив формалар белән баетуны, һәр баланың эмоциональ иминлеге һәм төрле яклы үсеше өчен педагогик коллективның җаваплылыгын арттыруны таләп итә. Бүгенге мәктәпкәчә мәгарифнең приоритетлары үзгәрү сәбәпле балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программаларын яңартырга кирәкле булды. Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре, яңа заман таләпләрен исәпкә алып, башка концептуаль нигезендә төзелгән программалардагы мәсьәләләрне һәм эчтәлекне әлеге документка мөстәкыйль рәвештә кертәләр. Шулардан чыгып, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем процессында "Физик үсеш", "Социаль-шәхси үсеш", "Танып белү-сөйләм үсеше", "Нәфис-нәфасәти үсеш" ёщм "Сөйләм үсеш" юнәлешләре булуы мөһим.
Белем бирү процессы "Туудан мәктәпкә кадәр" якынча балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы нигезендә төзелгән, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева мөхәррияте астында, 2012 ел, 2-е басма, «Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы»; К.В. Закирова, Р.А. Низамов, Мәгариф-2006, "Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы", Р.К.Шаехова, 2012. Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулинаның И.Җ. "Туган телдә сөйләшәбез" методик әсбап; Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина, Ф. В. Хәзрәтованың "Математикага өйрәнәбез" (Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма; Р. М. Зиннәтова, Л. Ә. Гәрәева "Сүрәтләү һәм кору эшчәнлеге" . Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре өчен методик кулланма эшчәнлек төрләренә нигезләнеп тулыландыра.

Программаның төп бурычлары - мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру, шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып, физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап үстерү, баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә әзерләү.

Бу максатлар бала эшчәнлегенең (уен, уку, иҗади, җыр-бию, хәрәкәт, элементар хезмәт) төрле процессларында тормышка ашырыла.

Программага куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренчел әһәмияткә ия:

- һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;
- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны инегральләштерү;
- тәрбия һәм белем процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү;
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә учреждение тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

Билгеле ки, программадагы тәрбияви бурычларны бары тик педагог балалар бакчасына килгән беренче көннәрдән үк балага, максатчан йогынты ясый алганда гына хәл итәргә мөмкин. Бала ирешергә тиешле гомуми үсеш һәр ул үзләштергән әхлакый сыйфатлар дәрәҗәсе һәм тәрбиячененң педагогик осталыгына, культурасына, балаларны яратуына бәйле. Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре педагоглары, баланың сәламәтлеге һәм төрле яклы үсеше турында кайгыртып, гаилә белән берлектә баланың тормышын бәхетле итәргә омтылырга тиешләр.

## Программа принциплары.

**Белем бирү процессын оештыру принциплары һәм алымнары.**

Программа нигезен бала үсешенә якын килүне-мәдәни, тарихи, заманлашкан мәгариф эшчәнлеге тәшкил итә.

Белем бирү мохитын оештыру принциплары:

Психологик комфорт принципы. Балалар һәм зурлар арасында бер-берсенә карата уңай караш тәрбияләү.

Эшчәнлек принципы. Төп эшчәнлек төрләрендә балаларның “ачыш”ларынаакцент ясала.

Бербөтенлелек принципы. Балаларда әйләнә-тирәне күзаллауларын, үзләре турында белемнәрен формалаштыру.

Минимакс принципы. Балаларны шәхси яктан үстерү өчен шартлар булдыру.

Сәнгать принципы. Белем бирү процессы һәр баланың сәнгать үсешен үстерергә юнәлдерелгән.

Вариатив принципы. Балаларга танып белү һәм күзәтүчәнлек эшчәнлегендә үзләренә кирәкле материалларны, хәрәкәт итү төрләрен һәм катнашучыларны сайлап алырга мөмкинчелек бирә.

Дәвамчанлык принципы. Мәктәпкәчә һәм мәктәп арасындагы белем бирүне оештыру буенча бәйләнешне саклау. Бу принциплар баланы шәхес буларак үстерү һәм аны ничек бар шулай кабул итәргә ярдәм итә.

## Приоритетлы юнәлеш

Мәктәпкәчә әзерлек төркеме балалары эшчәнлегендә танып белү үсеше приоритетлы юнәлеш булып тора. Аларга: танып белү, күзәтүчәнлек, әйләнә-тирәне күзәтү кирә.

Мәктәпкәчә әзерлек төркемендә тәрбия һәм белем бирүне оештыру эчтәлеге интеллектуаль һәм шәхси яктан баланың сәламәтлеген саклау, ныгыту; уен төрләре эшчәнлеге: уен, коммуникатив, хезмәт, танып белүне формалаштыру.

Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең формалары һәм төрләре: әңгәмә,дидактик уеннар, рәсемнәр карау, коллекция җыю, проектлар карау, викториналар, интегратив эшчәнлек, "Мин һәм табигать» экологик өстәмә программасы, шәхси эш, аерым эш.

**Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр**

Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге
Укыту-методик комплектында тупланган материаллар балалар бакчасы педгогларына балаларның сөйләмен үстерү,тирә-юнь,матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел,ә рәсем ясау,әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү,эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура  эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү,саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланыла һәм ныгытыла.
"Туган телдә сөйләшәбез"методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын,байлыгын аңларга,аны сиземләргә,үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга,тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә,туган телебезгә мәхәббәт, әти- әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт итәгать тәрбияләү, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык,шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.
Балалар "сүз", "аваз" терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлау, сүзгә игътибарлары арту, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табу, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтә.
Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишү өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары куллану. Алты яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.
Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре.**
Ирешелгән нәтиҗәләр: -безне нәрсә шатландыра
Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый.
Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмәт бирә ала.
Үзе, әти-әнисе турында сөйли белә.
Үзенең адресын, телефон номерын әйтә белә.
Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша. Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен аңлап, төгәл куллана ала.
Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча иҗади хикәя төзи белә.
Әсәрнең жанрын билгели ала.(әкият, хикәя, шигырь)
Китап геройларына карата үз мөнәсәбәтен белдерә ала.
Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сwйли.
Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр**.
Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый.
Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат аз бирә.

Үзе (фамилиясе, исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы сай. Бала күмәк сөйләмдә катнашмый. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча үзлектән хикәяләр сораулар ярдәмендә генә төзи.
Бала әсәрнең жанрын(әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәмннән башка билгели алмый. Китап геройларының кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый. Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәнгатьле итеп сөйләми.
Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый. Китаплар белән кызыксынмый.

## 2. Эш программасының максаты һәм бурычлары

**Эш программасының максаты:**

— баланың мәктәпкәчә балачагын тулы канлы уздыру өчен уңай шартлар тудыру, шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, хәзерге җәмгыятьтәге тормышка әзерләү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.

**Эш программасының бурычлары**:

• һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;

• төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелекле һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;

• балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия- белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;

• тәрбия-белем бирү процессын иҗади оештыру;

• белем бирү материалын куллануның вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;

• балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;

• мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм гаилә шартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;

• балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү.

**Эш программасының төп фикере** - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

**Эш программасының күрсәткече:**

*Белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;

*Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;

*Балаларның иҗади сәләтен ачу, сәләтлеләрне табу, шәхси үстерү өчен яңа технологияләр куллану;

*Балаларның мөмкинчелегеннән, кызыксынучанлыгыннан, сорауларыннан чыгып төрле төр эшчәнлекләрне үстерү;

*Эчтәлекле аралашуга, сөйләшүгә төзелгән шәхси һәм төркем белән эшчәнлекләр оештыру;

*Балага эшчәнлектә үзен күрсәтү, эчтәлеген сайлау, иптәшләр сайлау хокукы.

## 3.Программаны формалаштыруның принциплары

• баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;

• фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә кулланучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәктәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);

• тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);

• мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;

• балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;

• белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына нигезләнә;

• программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;

• белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә;

• төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрлеләндерүгә юл куя;

• мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелә.

**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**

1.Танып белү-сөйләм үсеше, социаль-шәхси үсеш, физик үсеш, нәфис-нәфәсәти үсеш.
2.Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы...)
3.Сәламәтләндерү һәм профилактика чаралары

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына түбәндәге бурычларны куя:
1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.
2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.
3.Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

4. “Татарстан Республикасы халыклары телләре” турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен сыйфатлы камиллләштерүне дәвам итү
Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар эшләп килә: татар теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы.

**4. Төркемнең комплектациясе**
**1 төркем турында белешмә**

| № төркем | Балаларның яше | Күплек саны | малайлар | кызлар | Балалар составы | Барлык балалар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | 6 -7 яшь | 27 | 13 | 14 | 27 | 27 |

**Төркемдә гаилә составы:**

| Татар гаиләсе | Катнаш гаилә |
|---|---|
| 12 | 15 |

**5. Балаларның яшь үзенчәлекләре**
**Мәктәпкәчә эзерлек төркеме (6 -7 яшь)**

Мәктәпкәчә әзерлек төркеме балалары эшчәнлегендә танып белү үсеше приоритетлы юнәлеш булып тора. Аларга: танып белү, күзәтүчәнлек, әйләнә-тирәне күзәтү кирә.

Мәктәпкәчә әзерлек төркемендә тәрбия һәм белем бирүне оештыру эчтәлеге интеллектуаль һәм шәхси яктан баланың сәламәтлеген саклау, ныгыту; уен төрләре эшчәнлеге: уен, коммуникатив, хезмәт, танып белүне формалаштыру.

Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең формалары һәм төрләре: әңгәмә,дидактик уеннар, рәсемнәр карау, коллекция җыю, проектлар карау, викториналар, интегратив эшчәнлек, “Мин һәм табигать» экологик өстәмә программасы, шәхси эш, аерым эш.

Бу яшьтә баланың сөйләме төрле контингент кешеләре (өлкәннәр һәм яшьтәшләр, таныш һәм таныш булмаган кешекләр) белән аралашуга мөмкинлек бирә. Балалар авазларны дөрес әйтү генә түгел, фонемаларны һәм сүзләрне таныйлар. Төрле орфологик системасын узләштерү аларга исемнәрнең, фигыльләрнең һәм сыйфатларның катлаулы грамматик формаларын төзергә мөмкинлек бирә.
Туган телгә карат тотрыклы кызыксыну үсә. Мәгълүмати – аралашу технолигияләре кулланып аралашырга өйрәнәләр, аудио – видеоязмалар, уку- укыту методикасы комплектларын кулланып предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләр һәм сүзтезмәрне сөйләмдә, аралашуда актив кулланалар. Гади аралашу кирэк булган сөйләм берәмлекләре белән балаларның лексикасы байый, байлыклары арта...

Бу яшьтәге балалар төзелеше ягыннан катлаулы булмаган һәм сорау җөмләләр төзиләр. татар телендә сөйләшүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белергә, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышалар. Телне беклүләренә дә карамастан диалогларда катнашырга омтылалар. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары бик еш сөйләмдә катлаулы җөмләләр кулланалар. 6- 7 яшьлек баланың сүз байлыгы арта. Диалог төзегәндә бала сорауларга тулы

җавап бирә, һәм үзе сораулар бирергә, әңгәмәдәшен аңларга тырыша. Монологик сөйләмдә рәвештә үсә. Балалар эзлекле һәм бәйләнешле итеп сөйли алалар.

## II Эчтәлекле бүлек

### 1. Белем бирү эшчәнлегенең тематикасы.

| Тема | Белем бирү эшчәнлеге | Йомгаклау эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Мәктәп – белем йорты (август ае 4атна -1сен ае 1 атна ) | Балаларда мәктәп белән кызыксыну хисләре уяту, белем алырга омтылыш тәрбияләү; сораулар ярдәмендә балаларның сөйләм телен үстерү, сөйләшерә этәрү; балаларны мәктәп тормышы белән таныштыру. | “Белем көне”- бәйрәме “ |
| Көз (сентябрь ае 2 -4 атна ) | Табигатьтә көз фасылы һәм андагы үзгәрешләрне күзаллау; көзнең матурлыгын күрә һәм соклана белүләренә ирешү; балаларда эстетик хис, күзәтүчәнлек,игътибарлык, кызыксынучанлык тәрбияләү; сүз байлыгын диалогик сөйләмне үстерүне дәвам итү; җәй һәм көз фасылларының үзгәрешләрен аера һәм күрә белүләренә ирешү. | “Көз-“бәйрәме , иҗат эшләр күргәзмәсе. |
| Минем шәхәр,илем, галәм (октябрь ае 1 -2 атна ) | Балаларда сәламәтлек, сәламәт кеше төшенчәсе булдыру, үзенең сәламәтлеген сакларга теләк тудыру.Сәламәтлек турында күзалларын киңәйтү. Балаларда сәламәт яшәү рәвешенә аңлы караш булдыру, сәламәт яшәү омтылышы тәрбияләү. | Ачык сәламәт көне |
| Халык ара бердәмлек көне ( 3ай октябрь -2 атна ноябрь ) | Балаларда Туган ил ,дәүләт бәйрәмнәре турында белемнәрен киңәйтү.Ил тарихына кызыксыну үстерү.Үз иленә горурлык, мәхәббәт хисләрен тәрбияләү. | “Халык ара бердәмлек көн бәйрәме. Балаларның иҗат эшләр күргәзмәсе. |
| Яңа ел (3 атна ноябрь-4 атна декабрь ) | Кыш белән танышыны дәвам итү, кыш фасыллары турындагомуми күзаллау булдыру.Төрле халыкларның Яңа ел бәйрәмен ничек билгеләп үтүләре турында мәгълүмат бирү.Әдәби сөйләмне үстерү. Үз кулларың белән бүләкләр ясарга өйрәтү хәм якыннарыны бәйрәм белән котларга омтылыш тәрбияләү. | “Яңа ел”- бәйрәме Балаларның иҗат эшләр күргәзмәсе. |
| Кыш (гыйнвар ае 1-4 атна) | Балаларның кыш фасыллары турындагы белемнәрен системалаштыру; бәйләнешле сөйләмне, логик фикерләү сәләтен үстерү, сыйфатлпрны дөрес , урынлы кулланырга өйрәтү;Табышмаклар,хикәяләр , шигырьләр аша кыш аеның матур булуын аңлату, табигатьнең матурлыгын күрә белергә | “Кыш” –бәйрәме Балаларның иҗат эшләр күргәзмәсе. |

| | | |
|---|---|---|
| | өйрәнү. Балаларда су һәм боз белән эксперимент үткәрү аша тикшеречәнлеккә, танып белүгә башлангыч кызыксыну формалаштыру. Табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. | |
| Ватанны саклаучылар көне (февраль ае 1-3 атна) | Балаларның туган илгә карата белемнәрен һәм дәүләт бәйрәмнәре турында белемнәрен арттыру. Төрле яштәш милләтләренә карата изгелекле һәм хөрмәт формалаштыру. Хәрби һөнәр, хәрби техника атамаларын белеп истә калдыру һәм бу сүзләрне сөйләмдә кулланырга өйрәтү.Ватанны саклаучыларга карата ихтирам тәрбияләү. | “Ватанны саклаучылар көне” –бәйрәме Балаларның рәсемнәр күргәзмәсе. |
| Халык ара хатын кызлар көне (4атна феврал ае-1атна март ае) | Әниләргә,әбиләргә багышланган шигырльләр белән танышу; Поэтик сөйләм күнекмәләрен, социаль күнкмәләрне үстерү.Әниләргә һәм әбиләргә хөрмәт,җылы хисләр тәрбияләү,әдәплелек һәм итагатьлелек күнекмәләре булдыру. Үз кулларың белән бүләкләр ясарга өйрәтү хәм якыннарыны бәйрәм белән котларга омтылыш тәрбияләү. | “8март” –бәйрәме Балаларның иҗат эшләр күргәзмәсе. |
| Халык бәйрәмнәре һәм гореф – гадәтләре( март ае 2-4атна ) | Башка милләт халкына дус тойгы тәрбияләү.Идел буе халыкның тарихы, мәдәнияте ,гореф-гадәтләре кызыксыну камилләштерү. Татар халкының декоратив кулланма сәнгате турында күзаллауларын киңәйтү.Гжель ,Городец,Полхов-Майдан эшләнмәләре характерлы өлешләре белән танышу | Милли бәйрәм Балаларның иҗат эшләр күргәзмәсе. |
| Исәнме, яз! (апрель ае 1-2 атна) | Балаларның язгы табигатьтәге үзгәрешләр турында күзаллауларын киңәйтү һәм үзенчәлекләрен тасфирлап сөйләргә өйрәтү. Күчмә кошларга ярдәм итәргә кирәклеге турындагы фикерне .һәм язгы күренешләр белән кызыксынуларын үстерү. Табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә өйрәтү. | “Нәүрүз”- бәйрәме Язгы кыр эшләре көне Балаларның иҗат эшләр күргәзмәсе. |
| Җиңү көне өчен сезгә зур рәхмәт! (3атна апрел ае-1 атна май ае) | Балаларның Бөек Ватан сугышы турында белемнәрен системалаштыру. Геройлар һәм җиңү яулаган каһарманнар турында мәгълүмат бирү.Патриотик хисләр,Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. | “Җиңү көн” – бәйрәме Балаларның иҗат эшләр күргәзмәсе. |
| Җәй (май ае 2-4 атна )Җәй айларында балалар бакчасы, каникул вакыты буенча эшли. | | |

| | | |
|---|---|---|
| (1атна июнь-<br>3атна август) | | |

## Вариатив өлеш

Шаехова Р. К. Региональная программа дошкольного образования. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. – РИЦ, 2012. – 208 с.

## Белем бирү олкәләренең эчтәлеге

### ФИЗИК ҮСЕШ

#### «Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе

*«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга* юнәлдерелә ***һәм белем бирү бурычларын*** *билгели.*
Программада физик тәрбиянең сәламәтләндерү, тәрбия һәм белем бирү бурычлары билгеләнгән. Баланың тормышын саклау һәм сәламәтлеген ныгыту, аңарда күңел күтәренкелеге булдыру; негатив эмоцияләрдән һәм нервлары бозылудан саклау, бала организмының бар функцияләрен камилләштерү; тулы физик үсеш, физик культура нигезләрен формалаштыру; көндәлек физик күнегүләргә ихтыяҗ, уңай әхлакый сыйфатлар һәм ныклы ихтыяр тәрбияләү күздә тотыла.

Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләрендә физик тәрбия махсус физкультура, шулай ук уен эшчәнлегендә һәм балаларның көндәлек тормышында гамәлгә ашырыла**.**

Балаларның организмнарын чыныктыру, сәламәтлекләрен ныгыту эшен дәвам итү, аларда сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү. Хәрәкәт эшчәнлеге вакытында мөстәкыйльлекләрен, иҗади сәләтләрен үстерү, хәрәкәтләрне башкарганда үзеңнең гамәлләреңә бәя бирергә өйрәтү. Спортка карата кызыксыну, мәхәббәт тәрбияләү.

**Физик культура.**

Балаларда көндәлек хәрәкәт эшчәнлегенә ихтыяҗ формалаштыру.
Һәр төр эшчәнлектә гәүдәне туры, төз тотарга гадәтләндерү.
Төп хәрәкәтләрне башкару осталыгын камилләштерү; хәрәкәтләрне җиңел, төгәл итеп башкару.
Йөргәндә һәм йөгергәндә, бер алган темпны саклый белү күнекмәләрен ныгыту.
Йөгереп килеп йомшак түшәмгә, биеклеккә һәм озынлыкка сикергәндә, йөгерү белән этелеп алга ыргылуны яраштырырга өйрәтү.
Ыргыту вакытында кул чуклары хәрәкәтен камилләштерү.
Гимнастика стенасының бер аралыгыннан икенче аралыгына диагональ буенча үрмәләргә өйрәтү.
Бер урында торган һәм йөргән килеш тиз генә күченеп тезелергә; бер рәттә, колоннада, түгәрәктә тигезләнергә, күнегүләрне бирелгән темпта тигез башкарырга өйрәтү.
Психофизик сыйфатлар: көч, тизлек, түземлек, җитезлек һәм осталыкларын үстерү.
Статик һәм динамик тигезлекне саклау күнегүләре эшләү; хәрәкәт координациясен һәм тирә-юньдә ориентлаша белүләрен үстерү.
Спорт күнегүләре башкару күнекмәләрен ныгыту.

Баланың һәрьяклы үсешен тәэмин итү. Түземлек, үз дигәнендә нык торучанлык, тәвәкәллек, кыюлык, оешканлык, башлап җибәрү осталыгы, булдыклылык тәрбияләү.

Мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтле уеннар оештырырга, үз уеннарын, уен вариантларын уйлап табарга өйрәтү эшен дәвам итү.

Физкультура һәм спорт өлкәсендә ирешкән кайбер уңышлар, спорт вакыйгалары турында мәгълүмат бирү.

**Ел ахырына үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр.**

Төп хәрәкәтләрнең барлык төрләрен (йөрү, йөгерү, сикерү, ыргыту, үрмәләү) дөрес башкару.

40 см биеклектән йомшак өслеккә сикерү, йомшак итеп җиргә төшү; баскан җирдән озынлыкка (100см чамасы), йөгереп килеп озынлыкка (180 см), йөгереп килеп биеклеккә (50 см дан да ким булмаган арадан); төрле ысуллар белән кыска һәм озын сикергеч аша сикерү.

Эченә әйбер тутырылган тупларны (авырлыгы 1 кг) ыргыту; 4-5 м арадан горизонталь һәм вертикаль ноктаGarга , хәрәкәттәге ноктага төбәп ыргыту, сул һәм уң кул белән 5-12 м ераклаккапредметларны ыргыту.

Физик күнегүләрне төрле башлангыч торыштан төгәл һәм ритмик рәвештә яңгыраган музыкага яраштырып, тәрбиячинең күрсәтмәләре буенча дөрес итеп башкару.

Гәүдәне төз, дөрес тоту.

Спорт элементлары кергән уеннарда (бадминтон, баскетбол, футбол, хоккей, өстәл теннисы) актив уйнау.

Гидроаэробика күнегүләре башкару.

Хәрәкәт эшчәнлеге вакытында тәртиплелек, чыдамлык, иҗади сәләт һәм мөстәкыйльлек күрсәтү, хәрәкәтләрне нәфис, нәзакәтле, матур итеп башкару.

**Саф һавада хәрәкәтле уеннар**

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

## «СОЦИАЛЬ-ШӘХСИ ҮСЕШ»

Мәктәпкә хәзерлек төркемендә мәктәпкәчә яшь чоры тәмамлана. Балалар кешелек культурасының аерылгысыз өлеше булган әйберләр дөньясы белән танышалар, кешеләр белән позитив аралашу формаларын үзләштерәләр.

Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт булдыру, бергәләшеп уйнау, эшләү, шөгыльләнү күнекмәләре бирү эшен дәвам итү, бер-берләренә ярдәшмләшеп, килешеп уйнау, шөгыльләнү күнекмәләрен ныгыту, уй гамәлләре белән өлкәннәрне сөендерәсе килү омтылышларын хуплау.

Әйләнә-тирәдәге кешеләргә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү эшен дәвам итү.Әңгәмәдәшен тыңлый белергә, кирәкмәгәндә аны бүлдермәскә, өлкәннәрнең сөйләшүенә кушылмаска өйрәтү. Кечкенәләр турында кайгыртучанлык тәрбияләү, аларга ярдәм күрсәтү. Өлкән кешеләргә, аларның хезмәтенә һәм ялына хөрмәт белән карарга, кайгыртучанлык күрсәтергә, үтенечләрен теләп үтәргә, кирәк икән, үзенең ярдәмен күрсәтә белергә өйрәтү.

Гаделлек, тыйнаклык, ярдәмчеллек, кеше хәленә керә белү, күмәклек кебек сыйфатлар формалаштыру.
Ихтыяр сыйфатлары үстерү: үз теләкләреңне чикли, максатка ирешүдә килеп чыккан каршылыкларны җиңә, өлкәннәрнең таләпләренә буйсына һәм тәртип кагыйдәләрен үти белү, үзеңнең эш-гаәлләреңне уңай үрнәккә охшатып башкару.
Сөйләм әдәбенә өйрәтү эшен дәвам итү. Сөйләмдә "исәнмесез", "саубулыгыз", "зинһар", "гафу итегез", "рәхмәт" кебек ягымлы сүзләрне куллану, активлаштыру.
Малайлар һәм кызларда аларның җенесләренә хас сыйфатлар тәрбияләү эшен дәвам итү.
Тирә-юньдәге чынбарлыкка үз мөнәсәбәтеңне белдерү һәм аны аңлатуга омтылыш тәрбияләүне дәвам итү.
Үзе һәм иптәшләренең кылган эшләренә гадел бә бирергә өйрәтү, үз фикереңне тыныч кына яклый белү.

Үз халкының мәдәнияте белән кызыксынуларын арттыру, башка халыкларның мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү. Сюжетлы-рольле уеннар өчен темалар төрлелегән хуплау; әйләнә-тирәдән, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләреннән, телетапшырулардан, шәһәр (авыл) буенча экскурсияләрдән, күргәзмәләрдән, походлардан алган белемнәргә нигезләнеп, сюжет үсешенә ярдәм итү.

Балаларның шартлы формада милли уенчыкларны, кулдан ясалган уенчыкларны файдаланган; тормышта булган хәлләрне, Идел буе халыклары әкиятләре сюжетларын, мультфильмнарны һ. б.ны чагылдырган шәхси һәм күмәк режиссерлык уеннарына булышлык күрсәтү.

Балаларның артистлык сәләтләрен үстерү, аларны сәхнә сәнгатенә тарту: концертлар кую, татар җырларын җырлау, Идел буе, халыклары биюләрен башкару, спектакльләрдән күренешләр күрсәтү. Яшьтәшләре, әти-әниләр һәм кунаклар алдында чыгыш ясарга мөмкинлекләр булдыру.

Инициативалылыкны, халык уеннары кагыйдәләрен үтәүне, тигез хокуклы партнёр позициясен ала белүне хуплау.

Белем өлкәсе "Социаль- шәхси үсеш" җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.Планлаштыру интеграция принциплары, төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

***Ел ахырына үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр:***
Мөстәкыйль рәвештә билгеле бер эзлеклелектә киенә һәм чишенә, киемне дөрес һәм пөхтә итеп шкафка урнаштырырга, аяк киемен урынына куярга;
Тере почмакта кизүлек вазыйфаларын мөстәкыйль башкара алуларына ирешү;
Эшчәнлек һәм уеннар өчен кирәкле материалларны әзерләү.

## «Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе

*«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм* **белем бирү бурычларын** *билгели*

### Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру

Балаларда мөстәкыйльлек, җаваплылык хисе үстерү; тормыш һәм сәламәтлекләрен саклау өчен, үз-үзеңне дөрес тотуның әһәмиятен аңлауларына ирешү.

Таныш булмаган кешеләр белән мөмкин булган һәм очраклы очрашулар һәм аралашу барышында балаларда үзләрен ничек тотарга кирәклеге турында ачык күзаллау

булдыру. Таныш булмаган кеше белән үзең генә калу һич тә ярамавына һәм куркынычлыгына игътибарларын юнәлтеп, балалар белән шундый очраклы очрашулар вакытында килеп чыккан хәлләрне бергәләп карау һәм фикер алышу.

Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру

Хәрәкәт юнәлешен (сүзле яки җаваплы) сигнал буенча алыштырып, «үзеңнән» һәм «үзеңә таба», бирелгән юнәлештә хәрәкәт итү; бер урыннан икенче урынга мөмкин булган күчешләр турында килешеп, әйләнә-тирәне үзләштерү; уен барышында объекттан (хәрәкәт итүче машина, поезд) хәрәкәт чагыштырмалылыгын билгеләргә өйрәтү.

Әйләнә-тирәдәге предметларның бер-берсенә карата булган урыннарын мөстәкыйль ачыклый белүләренә ирешү: өстенә - өстендә, буенча - астында, сулда - уңда, артында - алдында, янында, янәшәсендә, арасында, уртасында, өстәрәк - астарак. Тирә-юньдәге кешеләр һәм предметлар арасында үзеңнең торган урыныңны билгеләү күнекмәләре үстерү.

Светофорның төсләрен (ике яклы, җәяүле өчен), «Балалар», «Хәрәкәт тыела», «Җәяүлеләрнең хәрәкәте тыела», «Велосипедлар хәрәкәт итү тыела», «Велосипед юлы», «Хастаханә» һ. б. юл хәрәкәте билгеләренең зурлыгын, төсен һәм формасын, регулировщик таягының төсен ачыклау нигезендә, сенсор сиземләү күнекмәләре формалаштыру.

Балаларга югары куркынычлык зоналары турында сөйләү. «Тайгак юл», «Куркыныч борылыш», «Юл эшләре», «Кыргый хайваннар», «Шлагбаумлы тимер юл чаты» һ. б. кисәтүче юл билгеләре белән таныштыру, аларның охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү.

Балаларны берничә полосалы хәрәкәт булган юлны чыгу алгоритмы белән таныштыру; юлларда, юл аркылы чыкканда, тәртипкә салына торган урам чатларын чыкканда ориентлашырга күнектерү. Балаларны «юл билгесе» төшенчәсе, юл чатларында җәяүлеләр хәрәкәтен тәртипкә сала торган «Җәяүлеләрнең җир асты юлы», «Җәяүлеләрнең җир өсте юлы» билгеләре белән таныштыру.

Хәрәкәтне сигналлар ярдәмендә җайга салучы ЮХИДИ инспекторы эшчәнлеге белән таныштыру, җәмгыять өчен аның хезмәтенең әһәмиятлелеген бәяләү күнекмәләре үстерү.

Балаларның махсус транспорт чаралары билгеләнеше («ашыгыч ярдәм» машинасы, «полиция» машинасы, «янгын сүндерү» машинасы һ. б.) турындагы белемнәрен ачыклау; сигнал тавышларына игътибар итәргә, аларны аера белергә өйрәтү; кайбер аерым очракларда махсус транспорт чараларының юл йөрү кагыйдәләрен бозу мөмкинлегенә игътибар иттерү.

Метрода: вагонда (ишекләргә сөялмәү, чыгарга алдан әзерләнү), станциядә (бер юнәлештә хәрәкәт итү, тыелган сызыкка басмау), экскалаторда (уң якта басу, үз хәрәкәтеңне экскалатор хәрәкәтенә яраклаштырып керергә һәм чыгарга әзерләнү); турникетлар аша үткәндә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Метрода, юлларда, шәһәр (авыл) урамнарында үз-үзеңне куркынычсыз тотуның мөһимлеген аңларга ярдәм итү; әхлакый аралашу үрнәкләре («рәхмәт», «рәхмәтлемен сезгә», «гафу итегез», «рәхимле булыгыз», «мөмкин булмасмы» һ. б.) биреп, гади этикет кагыйдәләрен үзләштерергә булышу.

Җәмәгать урыннарында үз кыланышыңны һәм башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү; балаларның юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләрен үтәмәгән очракта килеп чыккан күңелсез хәлләрне, аларның башка кешеләрнең эмоциональ халәтенә йогынтысын аңлауларына ирешү.

Үзең яшәгән җирлектә транспорт чараларының төрлелегендә ориентлашу күнекмәләрен үстерү: өйдән балалар бакчасына кадәр, үзәк мәйданга һ. б. җирләргә кадәр

нинди маршрут автобусы белән барырга мөмкин, әти-әниләр нинди транспорттан файдалана һ. б.

Балаларны машинада утырып йөрү кагыйдәләре белән таныштыру: балалар урындыгында (креслосында) утыру һәм каеш белән эләктереп кую, машина йөртүченең игътибарын читкә юнәлдермәү, тәрәзәдән башны чыгармау, үзең белән очлы предметлар алмау; үз хәрәкәтләреңне контрольдә тотарга өйрәнү.

Баланы үз фамилиясен, тулы исемен, яшен әйтергә өйрәтү. Тору урынының адресын, телефонын, якындагы тукталыш исемен әйтү һәм полиция хезмәткәренә ярдәм сорап эндәшү күнекмәләрен булдыру.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буйлап, елан- сымак, ике яки өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәнүне дәвам итү; үз хәрәкәтләрең белән идарә итә белергә, велосипедта, самокатта йөрү урыннарын билгеләргә өйрәтү.

Балаларның хәрәкәтле уеннар, спорт һәм эстафета уеннары («Каршылыклы юл», «Күңелле ярышлар» һ. б.) оештыру инициативасын хуплау.

Балаларга таныш булган юл билгеләрен, урам чатлары, тукталышлар, ике яклы хәрәкәт, төрле билгеләнештәге транспорт хәрәкәтен файдаланып, җәяүлеләр һәм пассажирлар булып уйнарга мөмкинлекләр бирә торган уен ситуацияләре тудыру һәм юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү өстендә эшләү.

Танып белү бурычларын үтәгәндә модельләштерү ысулын куллану: күләм һәм киңлек бәйләнешләрен билгеләү («Бүлмә буйлап сәяхәт», «Бала кая киткән?» һ. б.).

Чынбарлыкта булган, вербаль һәм вербаль булмаган уйлап чыгаруларга таянып, эчке программалаштыруның гади операцияләренә өйрәтү: ситуацияләрне уйнап күрсәтү, пространствода биналарның, транспорт чараларының, җәяүлеләр, юл билгеләренең урнашу макетын һәм моделен ясау күнекмәләре формалаштыру.

Алынган мәгълүматны (су, җир өсте, тимер юл, һава, җигүле транспорт) гомумиләштерергә һәм аны мөстәкыйль эшчәнлектә файдалана белергә өйрәтү («Нәрсә артык?», «Ав- тоюллар лотосы», «Юл доминосы» һ. б.).

Балаларның проблемалы характердагы сораулар бирүләрен хуплау, укыганнары буенча фикер алышуга теләк тудыру («Светофор эшләмәсә, нәрсә булырга мөмкин?», «Әгәр туп транспорт йөри торган юлга тәгәрәп чыкса, нишләргә?» һ. б.). Балаларны проблемалы ситуацияләрне чишәргә генә түгел, ә бәлки үз фикерләрен әйтеп бирергә өйрәтү.

Юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләренең кайберләрен ныгыту максатыннан, уйлап чыгарган әкиятләрдән, тормыш тәҗрибәләреннән алынган хикәяләр, шигырьләрдән, үзләре ясаган рәсемнәрдән (аппликацияләрдән) китап-җыентык төзүләрен хуплау.

Мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә эзләп табарга мөмкинлек бирү.

***Экологик аң алшартларын формалаштыру***

Табигатьтә үз-үзеңне тоту культурасын формалаштыруны дәвам итү. Туган як табигате өчен куркыныч булган кайбер чыганаклар турында сөйләү (агачларны кисү, урман янгыннары, көчле салкыннар, сулыкларны пычрату һ. б.).

Табигать белән кешенең үзара бәйләнеше, әйләнә-тирәнең кешенең сәламәтлегенә йогынтысы турында күзаллаулар булдыру.

Балаларны хуҗасыз хайваннар белән очрашканда мөмкин булган куркыныч хәлләр турында искәртү.

## «Хезмәт» белем бирү өлкәсе

«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә ***һәм белем бирү бурычларын*** билгели.

Татар халык әкиятләре («Өч кыз», «Үги кыз», «һөнәрле үлмәс» һ. б.) ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын әкияттә хезмәт итүче геройларга юнәлдерү. Балаларның эш барышларын Г. Тукай шигырьләрендәге («Кызыклы шәкерт», «Шаян песи» һ. б.) юллар белән бәйләү.

Туган шәһәрдәге (авылдагы) укытучы, нефтьче, сыер савучы һ. б. һөнәр ияләре турында күзаллауларын формалаштыру.

Балалар бакчасы участогында тәрбияче белән эшләгәндә, балаларның актив катнашуын булдыру: яфраклар коелгач, кулларыннан килгәнчә участокны җыештыру, шәһәрдә яшәүче кошларга өстәмә азык бирү.

Гаилә бәйрәмнәренә әзерләнгәндә, өлкәннәргә кулларыннан килгәнчә булышу, өйдә үз вазифаларын үтәүгә тарту.

## «Танып белү үсеше»

Бала һәм әйләнә-тирә: Табигый тирәлек. Экологик күзаллаулар формаштыру

«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм *белем бирү бурычларын* билгели.

Татарстан - күпмилләтле республика. Казан - эре промышленность үзәге, Россиянең борынгы шәһәрләреннән берсе. Казан - республиканың һәм бөтендөнья татарларының башкаласы. Казанда Президент, Татарстан Хөкүмәте һәм шәһәр мэры эшлиләр. Шулар турында балаларда күзаллаулар булдыру.

Балаларга туган як турында мифлар, легендалар, тарихлар сөйләү. Туган шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары, бик күптәнге вакыйгалары, тарихи истәлекләре, музейлары, урамнары белән таныштыру.

Татарстан Республикасының төп символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру. Балаларга үз халкыңның бер өлеше булуларын аңлату.

Татарстан Республикасының географик урыны белән таныштыру (картада яки глобуста республиканың территориясен, Кама һәм Идел елгаларын, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларын, Кабан күлен, тирә-як күл һәм елгаларын билгеләү).

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру. Милли бәйрәмнәр (Нәүрүз бәйрәме, Корбан бәйрәме, Сабантуй, Нардуган һ. б.) турында күзаллаулар булдыру. Башка милләтләргә карата хөрмәт һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү.

Милли һәм бөтендөнья культураларының үткәне һәм бүгенгесе белән танышуга тарту. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күренекле эшлеклеләрнең (шагыйрьләр: Г. Тукай, М. Җәлил, Р. Миңнуллин һ. б., язучылар: А. Алиш, Р. Батулла һ. б., рәссамнар: Х. Якупов, Х. Казаков һ. б., скульптор Б. Урманче һ. б.) тормыш һәм иҗатлары белән таныштыру. Аларның тормышлары һәм эшчәнлекләренә карата кызыксыну уяту.

Балаларның кызыксынуларын исәпкә алып, туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү.

Кешеләрнең табигатьне саклау буенча эшчәнлеге белән таныштыру. Идел-Кама дәүләт тыюлыгы, «Түбән Кама» милли паркы, республиканың табигатен саклауда аларның әһәмияте турында сөйләү.

Тере һәм тере булмаган табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, туган як табигатенә үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен дип карау ярамаганлыгын аңлату, аны файдалануның беренчел күнекмәләрен булдыру («Әгәр мин һәм башка кешеләр дару үләннәрен тамырлары белән җыйса...»).

Туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү. Табигать объектларын үзенчәлекләре буенча классларга һәм төркемнәргә бүләргә

өйрәтү (ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, үлән үсемлекләр; урман, болын, бакча үсемлекләре; урман җиләкләре, гөмбәләр, бүлмә үсемлекләре (гөлләре); кыргый һәм йорт хайваннары, кышлаучы һәм күчмә кошлар, балыклар, бөҗәкләр һ. б.).

Республика территориясендәге хайваннарның яшәү рәвешен, аларның тышкы кыяфәт үзенчәлекләрен (гәүдә өлешләре, тәне нәрсә белән капланган), хәрәкәт итү ысулларын (шуыша, оча, йөзә), азыкларын; кайбер бөҗәкләрнең, җир-су хайваннарының, сөйрәлүчеләрнең яшәү мохитенә яраклашуларын күзәтергә өйрәтү. Хайваннарны тавышларыннан таныргa булышу.

Туган як табигатенең матурлыгын, аның форма, төс, исләр байлыгын күрә һәм тоя белү күнекмәләрен үстерү.

## « Элементар математик төшенчәләр формалаштыру »

Сан һәм санау.

10 эчендә тәртип буенча санау күнекмәләрен камилләштерү, саннарны унай һәм кире тәртиптә санау.

0-9 цифрлары белән таныштыру.

Саннар арасындагы бәйләнешләрне белүләрен ныгыту.

Телдән әйтелгән яки язып күрсәтелгән санның алдында килгән һәм аннан соң килгән санны әйтергә, төшереп калдырылган санны билгеләргә өйрәтү.

5-10 эчендәге саннарның берәмлекләрдән торган составы белән таныштыру. Санны ике санга таркату (10 эчендә күрсәтмәлелек нигезендә) һәм ике кечерәк саннанз уррак сан төзергә өйрәтү.

| Сөйләм теле үсеше.<br>Матур әдәбият белән таныштыру | Әңгәмә. “Минем гүзәл халкым”. | Рәсемнәр, яшел яулык.<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 144 бит.) | 1. Туган җирен, халкың, телең белән горурлану хисе тәрбияләү, Татарстанда яшәгән башка халыкларның мәдәниятен хөрмәтләү.<br>2. Балаларда халкыбызның туган җиренә, теленә, үткәненә, тарихына, мәдәниятына кызыксыну үстерү.<br>3. Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл кулланырга өйрәтүне дәвам итү.<br>Сүзлек: рәссам, композитор, җырчы. |
| Танып белү үсеше<br>ЭМКФ | “Аң-белемне үстерүгә күнегүләр” | Рәсемле карточкаар, кошлар, керпеләр, саннар, уеннар. | Логик фикерләүләрен үстерү, аң-белемне үстерүгә күнегүләр чишәргә өйрәтү, микъдар саны белән эшләүләрен камильләштерү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | «Күңелле саннар» | Саннар таякчыклары, Кюизенер таякчыклары, фигуралар, таратма материаллар (санау өчен). | Унга кадәр, тәртип буенча санауны кабатлау; конструктор ярдәмендә саннарны төзү, геометрик фигураларнын исемнәрен ныгыту; предметларнын пространствода урнашуын ныгыттыру; игътибарлыкны, логик фикерләүне үстерү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Кошлар өе» | Альбом бите, пумала, йорт кошлары төшерелгән рәсемнәр, карандашлар. | Балаларның фантазиясен үстерү; кошларны ясарга өйрәтү; табигаткә, кошларнга сак караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Саескан» | Альбом бите, пумала, саескан рәсемнәре, карандашлар. | Балаларның фантазиясен үстерү, кошларны ясарга өйрәтү, кошларны тышкы кыяфәте буенча аерырга өйрәтү, табигаткә, кошларнга сак караш тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кисеп ябыштыру | «Чәй сервизы». | Альбом бите, пумала, чәй сервизы төшерелгән рәсемнәр, карандашлар, клей, чәй сервизы трафарет. | Кайчы белән эшләү кунекмәсен ныгыту. Трафарет белән төшереп кисәргә өйрәнү (чәчәкләр, яфраклар). Төсләрне матур итеп сайлау кунекмәсен үстерү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | « Дымков хатын-кызы» | Дымков хатын-кызы, рәсемнәр, пластилин, такта, стек, юеш чүпрәк, су.<br>(Н.С.Голицына) | Дымков рәсеме турында белемнәрен үстерү; аңа гына хас булган бизәкләрне төшерергә өйрәтү; кул чукларын үстерү. |
| Танып - белү үсеше<br>Төзү | Табигать бүләкләреннән кул эше «Бозау» | Салам кисәкләре, ак кәгазь, кара кәгазь, тимер чыбык кисәге, клей, пумала, җепләр, кайчы. | Табигать материаллары белән эш итәргә өйрәтү;<br>Балаларның фантазияләрен үстерү;<br>Табигатькә сак караш тәрбияләү. |
| **Октябрь**<br>**III атна: “Гаилә”** | | | |
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br>Сөйләм теле | Иҗади хикәя төзү. «Тату гаилә» | «Тату гаилә» темасына балалар ясаган рәсемнәр.<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 174 бит) | 1. Гаиләдә бер-берсенә игътибарлылык, ярдәмләшү һәм дуслык, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3. Сөйләмдә гаилә әгъзаларын белдерә торган сүзләрне куллану күнекмәләре бирү, иҗади хикәя төзергә өйрәтү. Сүзлек: горурланам, тату, нәсел, язма яздым. |
| Танып белү үсеше<br><br>Танып белү һәм эзләнү | Шигырь уку: З.Туфайлова. «Минем гаиләм» | Рәсемнәр, фотоальбомнар.<br><br>(Матур әдәбият: К.В.Закирова. «Балачак аланы», 367 бит) | 1. Балаларда гаилә әгъзаларына ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.<br><br>2. Балаларда матур әдәбият әсәрләрен игътибар белән тыңлый белү, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>3. «Тату гаилә» дигән төшенчәнең асылын бирү.<br><br>Сүзлек: бишек, әрәм булу, бәрәкәт. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү | [п] авазын өйрәнү | Уен "Тишек туп", "Паровоз"<br><br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 28 бит) | [п] авазын аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү һәм фикерләү сәләтен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| Сөйләм теле үсеше.<br><br>Матур әдәбият белән таныштыру | Шигырь ятлау: Ә.Бикчәнтәева "Дәү әнием» | Рәсемнәр, фотоальбомнар.<br><br>(Матур әдәбият; К.В.Закирова «Балачак аланы», 367 бит.) | 1. Балаларда гаилә әгъзаларына, дәү әниләргә карата хөрмәт хисләре, ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.<br><br>2.балаларда матур әдәбият әсәрләрен игътибар белән тыңлый белү, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>3. "Дәү әнием" дигән төшенчәнең асылын бирү.<br><br>Сүзлек: бишек, әрәм, булу, бәрәкәт. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Танып белү үсеше<br>ЭМКФ | “Санны дөрес урнаштыр” | Саннар конструкторы, саннар, шакмаклы дәфтәр, ручка, уен: “Саннар буталган.”<br>(Т.М.Бондаренко 233 бит) | 1. 10 эчендә бер берәмлеккә киметү ысулы белән кирегә санарга өйрәтүне дәвам итү;<br>2. Вакытны сәгатьләр ярдәмендә саналуын аңлату, пространствода ориентлашуны ныгыту;<br>3. “Уртасыда, янында, алдында, артында, уңда, сулда сүзләрен дөрес кулллануны дәвам итү; |
| | «Планета - Венера» | Картинкалар-буяу өчен, геометрик фигуралар, схема – символлар.<br>(Перспектив план Е. А Мартынов, И.М. Сучков 29 бит.) | Логик фикерләүне үстерү, күплекне өч билгесе буенча<br>классификацияләргә өйрәтү (төс, форма, зурлык); танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын, диалог сөйләм, игътибарлылык, тәрбиячене биремнәрен үти белү осталыгын, мөстәкыйльлекне, кулларның вак моторикасын үстерү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Көзге каен” | Төсле кәгазьләр, гуашь, пумала №3 и №4<br>(Т.М.Бондаренко 424 бит.) | Агачның төп өлешләрен аерырга өйрәнү (кәүсә, ботак, яфрак); төсләрне дөрес сайларга, төртү ысуллары белән рәсем ясау осталыкларын үстерү; табигатькә сак караш тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Чыршы ботагы» | Балавызлы акбур, альбом бите, чыршы ботагы (Т.М.Бондаренко 426 стр0 | Традицион булмаган юл белән чыршы ботагы ясарга өйрәтү; төсләрне дөрес сайлау алымнарын үстерү; кул чукларын үстерү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Тимер юл» | Турыпочмак формасында тартма, клэй, кайчы. | Тимер юл транспорты белән якыннан танышу.Турыпочмаклы тартмадан тимер юл төзергә өйрәтү.<br>Сүзлек: цистерна, платформа |
| Танып - белү үсеше<br>Төзү | «Кузя һәм аның хуҗабикәсе өчен җиһазлар» | Төзү материаллары. | Элек өйрәнгән төзү алымнарын ныгыту. Конструктор ярдәмендә өй өченә җиһазлар төзергә өйрәтүне дәвам итү. Төзелешне матур итеп тулыландыру, үзеңнең схемаңны булдыру; күмәк эшләү теләге булдыру. |

| **Октябрь**<br><br>**IV атна: “Йорт җиһазлары”** | | | |
|---|---|---|---|
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Сөйләм теле | «Минем өем, өй җиһазлары» | рәсемнәр, йорт җиһазлары, туп, геометрик фигуралар.<br><br>Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 171 бит | 1.Балаларда гаилә әгъзаларына карата ихтирамлы мөнәсәбәт, йорт җиһазларына сакчыл караш тәрбияләү.<br><br>2.Балаларның йорт җиһазлары турындагы белемнәрен баету, тирәнәйтү, мөстәкыйль һәм гомумиләштереп фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>3.Балаларны, үз тәҗрибәләренә таянып, тәрбияче тәкъдим иткән темага сөйләргә өйрәтү.<br><br>Сүзлек: утыргыч, аркасы, түше, түбә, йорт җиһазлары, ашъяулык. |
| Танып белү үсеше<br><br>Танып белү һәм эзләнү | Әңгәмә. «Нәрсә ул электр һәм электр җиһазлары?» | Уен өчен парлы рәсемнәр, схема-рәсемнәр, ватман, төсле карандашлар.<br><br>Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 172 бит | 1. Кеше кулы белән эшләнгән әйберләргә карап соклана, хезмәт нәтиҗәләрен күреп горурлана белү хисләре тәрбияләү, электр җиһазларын кулланганда сак булырга өйрәтү.<br><br>2. Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү, алган белемнәрен көнкүрештә куллана белү сәләтен үстерү.<br><br>3. Эш урынында кешенең хезмәтен җиңеләйтүче, өйдә кеше өчен уңайлыклар тудыручы предметлар турында белемнәрен камилләштерү.<br><br>Сүзлек: электр тогы, электр җиһазлары. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сөйләм теле үсеше Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү | [м] авазын өйрәнү | Уеннар: “Утыр, утыр Мәликә”; “Җырчы” тизәйткеч<br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 31 бит) | [п] авазын әйткәндә сөйләм апараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү сәләтен үстерү; интонаия өстендә эшләү; логик һәм образлы фикерләүне үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| Сөйләм теле үсеше. матур әдәбият белән таныштыру | А.Алиш “Сертотмас үрдәк” әкияте “ | Рәсемнәр, туп, “Сертотмас үрдәк” мультфильмы<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 153 бит) | 1.А.Алиш әкияте буенча әхлакый сыйфатлар (серне саклый белү , иптәшләреңне авыр хәлдә калдырмау сыйфатларын) тәрбияләү.<br>2.Балаларның монологик сөйләм телен үстерү, тыңлап аңлау сәләтен ныгыту.<br>3.Балаларда әкиятнең төп идеясен аңларга, әкият геройларының кылган эшләренә дөрес бәя бирә белергә һәм әкиятнең эчтәлеген эзлекле итеп сөйләргә өйрәтү.<br>Сүзлек: бүрекле,төкле, сертотмас, гәүһәр. |
| Танып белү үсеше<br>ЭМКФ | Табышмаклар,<br>карточкалар буенча биремнәр “Тыңла һәм эшлә. | Карточкада рәсемнәр, турыпочмак төшерелгән кәгаз битләре, саннар, карандашлар,<br>(Т.М.Бондаренко 216 бит) | Күнегүне чишәргә һәм санарга өйрәтү; күрсәтмә-образлы фикерләүне, игътибарлылыкны, күреп хәтердә калдыруны, күзаллауны, диалогик сөйләмне үстерү; математика эшчәнлекләренә карата кызыксынуны үстерү, авыр хәлдә калганнарга ярдәм итәргә кирәклеген аңлату. |
| | «Күршеләр» | Уенчыклар,+,-, билгеләре, төсле кәгазләр;<br>(Перспектив план Е. А Мартынов, И.М. Сучков 30 бит.) | Бер төркемдәге предметларныж аерма якларын табырга,<br>+, -, = билгеләрен ныгыту, биремнәрне чишәргә һәм аның нинди өлешләрдән торганлыгын ачыклау, кәгазь яссылыгында ориентлашырга күнектерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Сирень чәчәкләре» | Гуашь, альбом бите, сирень чәчәгенең открыткасы, шырпы.<br>(Т.М.Бондаренко 497 бит) | Чәчәк атучы сиренне рәсемдә күрсәтергә өйрәтү. Акварель белән эшләү ысулларын (рәсем ясар алдыннан, пумаланы суга манып, һәр буяуга берәр тамчы су тамызып, буяуларны җебетергә; бер төстәге буяуның төрле төсмерләрен алу өчен, аны су белән сыекларга өйрәтү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Матур чәчәкләр» | 6 төрле гуашь, кәгазләр, пумала, су.<br>(Т.М.Бондаренко 496 бит) | Балалар теләге буенча ирекле рәсем ясау, төсләр сайлау мөмкинлеге бирү, балаларның кәефен күтәрү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Әвәләү | Филимон уенчыгы “Әтәчкәй” | Пластилин, такта,стек, салфеткалар<br>Филимон уенчыгы–сызгыра торган Әтәч. | Балаларны Филимон уенчыгы әвәләргә өйрәтү, әтәчкә карап дөрес формаларын туры китереп әвәләргә, эшләгән эшне сокланып карарга өйрәтү, кул моторикасын ныгыту. |
| Эстетик сәнгать үсеше<br>Кул эше | Композиция «Вазадагы чәчәкләр» | Картон бите, (12*12), кипкән чәчәкләр, клэй, пумала. | Әйләнә- тирәне күзәтүне дәвам итү.<br>Табигать материаллары белән эшләргә өйрәтү.<br>Иҗади сәнгать осталыгы үстерү. Матурлыкны күрә белергә өйрәтү. |
| Танып - белү үсеше<br>Төзү | «Транспорт өчен күпер» | Картон, клэй, кайчы. | Киң, тар күперләр төзергә өйрәтү. Нинди транспорт өчен төзүен ачыклау. |
| **Ноябрь** | | | |
| **I атна: «Ашамлыклар»** | | | |
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Сөйләм теле | Хикәя сөйләү: “Тәлинкәнең төбе нинди?” | Тәлинкәләр җыелмасы, туп.<br><br>(Матур әдәбият: К.В.Закирова «Балалар бакчасы», 511 бит.) | 1. Балаларда савыт – сабаларга карата сак караш тәрбияләү.<br><br>2. Әсәрнең төп идиясен аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирү кунекмәләрен, монологик сөйләмне үстерү.<br><br>3. Алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү.<br><br>Сүзлек: ашханә, тәлинкә төбе, аш тәлинкәсе, сай тәлинкә. |
| Танып белү үсеше<br><br>Танып белү һәм эзләнү | Ашханәгә экскурсия | «Пешекче» рәсеме, сюжетлы-рольле уен өчен кирәк-яраклар<br><br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 177 бит.) | 1. Балаларда өлкәннәр хезмәтенә ихтирам тәрбияләү.<br><br>2. Көндәлек туклану режимы турында төшенчә бирү, һәр төр ашка туры килүче ризыклар, аларның сәламәтлеккә тәэсирен ачыклау, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>3. Өйрәнелгән сүзләрнең сөйләмдә кулланылышын активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрнең мәгънәсен аңларга өйрәтү.<br><br>Сүзлек: ашханә, пешекче. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [VV] һәм [в] авазларын өйрәнү | Уеннар “Серле тартма”, “Паровоз һәм вагоннар”<br><br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 33 бит.) | [VV] һәм [в] авазларын әйткәндә сөйләм апараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү сәләтен үстерү; темп өстендә эшләү; игътибарлылык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Матур әдәбият белән таныштыру | Хикәянең эчтәлеген сөйләү: С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?» | Песнәк рәсеме.<br><br>(Матур әдәбият: К.В.Закирова. «Балачак аланы», 321 бит) | 1. Балаларда сөйләм әдәбе, бер-берсен тыңлый белү сыйфатлары тәрбияләү.<br><br>2. Күрсәтмә образлы фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>3. Балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга һәм хәтердә калдырырга ярдәм итү, текстның эчтәлеген тулы итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.<br><br>Сүзлек: тап-таза, сау-сәламәт, калак, капкалап. |
| Танып белү үсеше<br><br>ЭМКФ | “Атна көннәре,<br><br>геометрик фигуралар турындагы белемнәрне һәм кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту”. | Төсләр эталлоны, рәсемле карточкалар, уен: «5 математик кәрзин» В.Воскобович, цифрлар җыелмасы.<br><br>(Т.М.Бондаренко 219 бит.) | Атна көннәренең эзлеклелегенә төгәллек кертү, тәүлек өлешләре турындагы күзаллауны ныгыту, җиде көннең (тәүлекнең) атна төзүен, атнаның һәр көне үз исеме белән йөрүен, җиде көннең һәрвакыт бер тәртиптә килүе турындагы күзаллауны балаларга ирештерү; геометрик фигуралар турындагы белемнәрне һәм кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту; танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын үстерү: тикшерү, каршы кую, анализ, чагыштыру, абстрактлаштыру, сөйләм, зирәклек, тапкырлыкны үстерү. |
| | «Уен-күңел ачу» | Төрле уенчыклар,туп. | Игътибарлылык, логик фикерләү үстерү, балаларның кәефен күтәрү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Күчмә кошлар оча» | А4 бите, акварель, пумала, схемалар, гади карандаш.<br><br>(Т.М.Бондаренко 433 бит.) | Күчмә кошларның очып баруын сүрәткә төшерергә өйрәтү.<br><br>Табигаткә сак караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Кар кеше» Л.В.Кусакова | Кайчы, поролон кисәге, клэй ПВА, салфеткалар. | Балаларны яңа материал-поролон кисәге белән таныштыру. Анардан катлаулы булмаган уенчык-кар кеше ясарга өйрәтү. |
| Танып - белү үсеше<br>Төзү | «Яңа ел бәйрәменә-флажок» | Гирлянда үрнәкләре, шнур, клей, пумала, турыпочмаклы төсле кәгаз кисәкләре, шаблоннар: йолдыз,чәчәк.<br>(Бондаренко) | Турыпочмаклы кәгазьләрне урталай бөкләп флажоклар ясарга өйрәтү. Төрле төсләргә буяп кую. Үз куллары белән ясалган уенчыкларны чыршыга элеп кую. Үзләре эшләгән эшкә соклану хисе уяту, геометрик фигуралар турындагы белемнәрне һәм кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту. |
| **Ноябрь**<br><br>**II атна: «Милли киемнәр»** | | | |
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br>Сөйләм теле | Чагыштырма хикәя төзү. «Кием кешене бизи» | Предметлы рәсемнәр, татар һәм рус киемендәге курчаклар. | 1. Балаларда матурлыкны күрә һәм аны саклый белү сыйфаты, зәвыклылык тәрбияләү.<br>2. Балаларның акыл, хәтер, күзаллау, фикер йөртү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.<br>3. Татарстан Республикасындагы төрле халыкларның дус һәм тату яшәүләре турындагы белемнәрен камилләштерү.<br>Сүзлек: башмакчы, кунак кызы |
| Танып белү үсеше<br>Танып белү һәм эзләнү | Танышу уены: «Әбиемнең серле сандыгы» | Казан сынлы сәнгать музее залын сурәтләгән слайдлар яки рәсемнәр, милли киемнәр ясалган рәсемнәр, аудиоязмада «Авыл көе», «Кәләпүш» җыры (Р.Вәлиева сүзләре, Л.Батыр-Болгари көе). | 1. Балаларда татар милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренә кызыксыну тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле фикерләү сәләтен үстерү, сөйләмдә парлы,<br>кушма, ясалма сүзләр куллану күнекмәләре бирү.<br>3. Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә куллануны системалаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Сүзлек: бәби итәкле күлмәк, камзул, күкрәкчә, түбәтәй, йөзек, беләзек, чулпы. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [ф ]авазын өйрәнү | Табышмаклар; уен "Авыртамы" [ф] авазы кергән исемнәр<br>(Иң татлы тел – туган тел М.Ф.Кашапова 36 бит) | [ф] авазын әйткәндә сөйләм апараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү һәм образлысәләтен үстерү; интонаия өстендә эшләү; логик һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| Сөйләм теле үсеше.<br>Матур әдәбият белән танытыру | Шигырь уку: Р.Вәлиева. "Кәләпүшем, кәләпүш" | Киеме рәсемнәр, энҗе, мәрҗән.<br>Матур әдәбият: К.В.Закирова. «Балачак аланы», 498 бит | 1. Балаларда матур әдәбият аша милли киемнәргә карата кызыксыну уяту, аларның үзләренә генә хас булган нәфис бизәлешенә, уңайлылыгына соклану хисләре тәрбияләү.<br>2. Халкыбызның күңел бизәкләре белән якыннан таныштыру; сөйләм телен, фикерләү сәләтен, тнып белү активлыгын үстерү.<br>Сүзлек : кәләпүш, укалы, энҗе, мәрҗән. |
| Танып белү үсеше<br>ЭМКФ | Логик бирем. | Саннар, таблицалар, уеннар. | Кычкырып санау буенча күнегүләрне үтәү, хәрәкәтләрне санарга өйрәтү; саннар турындагы белемнәрне ныгыту; игътибарлылыкны, сөйләмне, логик фикерләүне, зирәклекне, күреп хәтердә калдыруны, күзаллауны үстерү; тырышлык, тыңлый белү сыйфатын тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | «Урман осталары» | Кюизенер таякчыклары (1 дән 5кә), төсле картоннан ясалган өй түбәләре 5 см, 10 см, 15 см, 20 см; өй төзү схемасы, таблица, төсле карандашлар.<br>(Е. А Мартынова, И.М. Сучкова 31 бит.) | Саннар турындагы белемнәрне ныгыту; игътибарлылыкны, сөйләмне, логик фикерләүне, зирәклекне үстерү.<br>Схема һәм Кюизенер таякчыклары белән төзелешләр төзү . |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Көзге чыршы һәм өрәнге агачы» | Чыршы агачы ясалган А-4 бите, гуашь, пумала, су.<br>(Т.М.Бондаренко 427 бит) | Агач төзелешен өйрәнү (кәүсә, ботак, яфрак)<br>Чыршы янына өрәнге агачы ясау. Яфракларын сары төскә кертү һәм чагыштыру. Мәңге яшел агач һәм яфрак коючы агач. Нәрсә уртак? Нәрсә белән аерылалар? |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Нинди төрле куаклар» (Гөлҗимеш). | Акварель, пумала №2, әз генә төс биргән А-4, чүпрәк, төрле куаклар рәсеме. | Балаларны куакларны аерырга, гөлҗимеш куагын һәм пумаланың очы белән ботак очларын ясарга өйрәтү.<br>Үсемлекләргә сак караш тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кисеп ябыштыру | «Кыргый хайваннар» | Кыргый хайваннар трафареты – куян,аю, картон, карандаш, кайчы, җепләр, пумала, кләй, бисер, салфеткалар. | Силуэтка төрле киселгән җепләр ябыштыру ысулы белән кыргый хайваннар ясарга өйрәтү.<br>Клейны тигез,юка гына сөртү алымнарын ныгыту. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Сал» | Җир һәм имән чикләвеге, чыбыклар, шырпылар, пумала.<br>( Гульянс) | Чыбыкларны тоташтырып сал ясарга өйрәтү.<br>Бергәләшеп дус-тату эшләргә, мөстәкыйллек тәрбияләү. |
| Танып - белү үсеше<br>Төзү | Куян “ | Ак кагәз бите , клей, шаблон зур, уранчы, кечкенә түгәрәкләр | Ак кәгаз битеннән зур , урта, кечкенә түгәкләр кисеп куян ясарга өйрәтү. Үзләре эшләгән эшкә соклану хисе уяту, геометрик фигуралар турындагы белемнәрне һәм кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| **Ноябрь**<br><br>**III атна: “Аралашу әдәбе”** | | | |
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Сөйләм теле | “Без дә хокуклы”. | Өстәл театры өчен материал, “Төлке, куян һәм әтәч”, “Зөһрә кыз”, “Золушка”, “Үги кыз” әкиятләреннән рәсемнәр, “Көлгенә – Золушка” мультфильмы.<br><br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 225 бит.) | 1. Балаларда уеннар аша бердәмлек, дуслык сыйфатлары, әхлаклылык тәрбияләү.<br><br>2 балаларның кызысынучанлыкларын, үзләренә, тирә-юньдәгеләргә карата игътибарлылыкларын логик фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>3. кеше хокуклары турында матур әдәбият һәм рәсем-иллюстрацияләр аша балаларга аңлату, белемнәрен ныгыту.<br><br>Сүзлек: хокук, пыскып, ятим, кайгыртулы. |
| Танып белү үсеше<br><br>Танып белү һәм эзләнү | Әңгәмә. «Тәмле сүз – җан азыгы» | «Өч кыз» мультфильмы<br><br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 20 бит) | 1. Уй-фикерләрен, уйларын тартынмыйча, үз сүзләре белән сөйләп бирү һәм тыңлый белү күнекмәләрен тәрбияләү.<br><br>2. Балаларның көнкүрешкә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен үстерү.<br><br>3. Балаларны төрле ситуацияләрне бәяләргә, аңлаешлы итеп әйтә белергә, катлаулы булмаган нәтиҗәләр ясарга өйрәтү.<br><br>Сүзлек: мәрхәмәтле, юмарт. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [т] авазын өйрәнү | Табышмаклар; уен “Капканы ач” “Паровоз”<br><br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 38 бит) | [т] авазын әйткәндә сөйләм апараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү, логик һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү; интонация, темп һәм дикция өстендә эшләү; игътибарлылык тәрбияләү |
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Матур әдәбият белән таныштыру | В.Осеева. «Тылсымлы сүз» | Туп.<br><br>(К.В.Закирова. «Балачак аланы», 266 бит.) | Матур әдәбият аша балаларның сөйләмендә ягымлы сүзләр куллануларына ирешү. Балаларның хәтер сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген дөрес интонация белән сөйләү күнекмәсе тәрбияләү.<br><br>Сүзлек: тылсымлы, тупас, зинһар, гаҗәпсенеп |
| Танып белү үсеше<br><br>ЭМКФ | Рәсемле карточкалар белән күнегүләр. | Рәсемле карточкалар , саннар, конструкторлар, уеннар.<br><br>(Т.М.Бондаренко 224 бит) | Тәртип буенча санауны кабатлау; конструктор ярдәмендә саннарны төзү, геометрик фигураларнын исемнэрен ныгыту; предметларнын пространствода урнашуын ныгыттыру; игътибарлыкны, логик фикерләүне үстерү. |
| | «Кәгазь битендә ориентлашу» | А-4 бите, рәсемнәр, фигуралар, саннар.<br><br>(Е. А Мартынова, И.М. Сучкова 31 бит) | Кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту; танып белүнең сенсор һәм логик ысулларын үстерү: тикшерү, каршы кую, анализ, чагыштыру, предметларның саны һәм аларның пространствода урнашулары арасындагы бәйләнешне аңлату; диалог сөйләм, игътибарлылык, биремнәрне үти белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | осталыгын, мөстәкыйльлекне, кулларның вак моторикасын үстерү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Ябалак» | Акварель, кара карандаш, төрле-төрле ябалак рәсеме. совы,<br>(Т.М.Бондаренко 442 бит) | Түгәрәк, овал формалары ярдәмендә ябалак рәсеме ясарга өйрәтү.<br>Кул чукларын үстерү.<br>Кошларга сак караш тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Карга оча». | Шакмаклы кәгазь битләре, буяулар, йомшак пумалалар.<br>(Занятия по ИЗО Г.С.Швайко 51 бит). | Очып, утырып, ботакта басып торучы карга рәсемен, чагыштырып карарарга һәм очканда канатлары ничек җәелүенә игътибар итеп ясарг өйрәтү. Кул чукларын үстерү.<br>Кошларга сак караш тәрбияләү |
| Эстетик сәнгать үсеше Әвәләү. | «Әкәм-төкәм» | Пластилин, такта, салфеткалар, стек, су, таяклар, бисер. | Пластилинны ике уч арасында тәгәрәтеп озынча формага китерергә,шул кисәктән әкәм - төкәм ясарга өйрәтү. Ясап беткәч уеннар уйнау эшкә бәяләмә бирү.<br>Үзеңнең эшеңә соклану хисе уяту, вак моториканы үстерү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Уенчыклар кибете» | Кәгазь һәм картон, кайчы, кләй, салфетка, конфетти, фломастерлар.<br>(Л.В.Кусакова) | Кәгазьне урталай бөкләп уенчыклар ясап кибеткә кую. |
| Тан- белү үсеше Төзү | «Шәһәр урамнары» | Төзү материалы, пассажир һәм йөк машиналары, транспорт, өйләр, агачлар, юл билгерәре.<br>(Бондаренко 98 бит) | Төзү материаллары белән шәһәр урамнары төзергә өйрәтү. |
| **Ноябрь**<br>**IV атна: “Савыт-сабалар”** | | | |

| Бүлек | Тема | Җиһазлар | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Сөйләм теле | Хикәянең эчтәлеген сөйләү: С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?» | Песнәк рәсеме.<br><br>(К.В.Закирова. «Балачак аланы», 321 бит.) | 1. Балаларда сөйләм әдәбе, бер-берсен тыңлый белү сыйфат- лары тәрбияләү.<br><br>2. Күрсәтмә образлы фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>3. Балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга һәм хәтердә кал- дырырга ярдәм итү, текстның эчтәлеген тулы итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.<br><br>Сүзлек: тап-таза, сау-сәламәт, калак, капкалап. |
| Танып белү үсеше<br><br>Танып белү һәм эзләнү | Савыт – саба кибетенә сәяхәт. | Савыт-сабалар<br><br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 41 бит.) | 1. Балаларда савыт- сабага карата сакчыл караш тәрбияләү.<br><br>2. балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү.<br><br>3.савыт- сабалар кибете турында белемнәрен тулыландыру, тәрбияче үрнәгендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү.<br><br>Сүзлек: чынаяк, чәнечке, пычак, чәйнек, кәстрүл, кашык, чүмеч, сатучы, сатып алучы, киштә. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [д] авазын өйрәнү. | Табышмаклар, “Паровоз” уен.<br><br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 40 бит.) | [д] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкләнләндерү күнекмәләрен бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтен үстерү; дөрес дикция, темп өстендә эшләү; игътибарлылык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Матур әдәбият белән таныштыру | Әңгәмә. «Кунак чакырдык» | Савыт-саба, милли ризык муляжлары, аудиоязмада «Кунаклар» җыры (Ш.Галиев сүзләре, С.Сабирова көе).<br><br>(Матур әдәбият: Ф.Ю.Юсупов. «Балалар бакчасы», 511 бит.) | 1. Балаларда кунакчыллык, кунакларга карата хөрмәт сыйфатлары тәрбияләү.<br><br>2. Балаларның игътибарлылыгын, диалогик сөйләмен үстерү.<br><br>3. Сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү, кунаклар белән аралашу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, өстәл әзерләү күнекмәләре булдыру.<br><br>Сүзлек: тартынмагыз, кыстап-кыстап, авыз итегез, гаеп итмәгез. |
| Танып белү үсеше<br><br>ЭМКФ | Уен: “Геоконт” | Карточкада рәсемнәр, биремнәр, уен “Геоконт”<br><br>(Т.М.Бондаренко 227 бит) | Логик фикерләүне үстерү. Биремнәрне чишәргә өйрәтү. Дуслык-татулык тәрбияләү. |
| | «Нильсның хикмәтләре» | Кюизенер таякчыклары, саннар 0 – 9, хәрефләр а, б, т, с, л; тау моделе; саннар таблицасы.<br><br>(Перспектив план Е. А Мартынов, И.М. Сучков 31 бит.) | Алу һәм кушу юлы белән мисаллар чишү ысулларын, логик фикерләүне үстерү; нокталарны симметрияле рәвештә урнаштырырга өйрәтү; күмәк эшләү күнекмәсе тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Миләш ботагында песнәкләр» | Акварель, пумала. Таякчыклар мамык башлы, салфеткалар, су.<br>(Т.М.Бондаренко 444 бит.) | Кул чукларын, иҗади сәләтне үстерү.<br>Кош рәсеме ясауны өйрәтүне дәвам итү.<br>Кышкы табигаткә, кошларга сак караш тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Иван – царевич һәм тутый кош» | Караңгы төстә кагәзләр, 25х25 см или 30х30с; гуашь, йөмшак кисточка, карандаш<br>( Занятия по ИЗО Г.С.Швайко 121 бит.) | Иҗади сәләтләрен үстерү; әкиятнең аталган бер эпизодын «Иван – царевич һәм тутый кош» рәсемгә төшерергә өйрәтү; кеше һәм кош арасындагы мөнәсәбәтне күрүне тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эстетик сәнгать үсеше Кисеп ябыштыру | «Астра» | Төсле картон, кәгазь, кләй, пумала, кайчы, салфетка, астра иллюстрациясе. | Кул чукларын, иҗади сәләтне үстерү;<br>Күптаҗлы, куе чәчәк кисәргә, матурлыкны күрергә өйрәтү; чәчәкләргә сак караш тәрбияләү. |
| Эст.- сәнг. үсеше<br>Кул эше | «Яңа ел гирляндасы» | Төсле кәгазьләр, кләй, кайчы.<br>(Голицына) | Төрле төсләр сайлап тар гына тасмалар кисәргә, төсләрне аралаштырып, тасмалардан боҗралар ябыштырырга өйрәтү;<br>Үзең ясаган матурлыкка соклану хисе тәрбияләү. |
| Тан- белү үсеше Төзү | “Түгәрәк эчендә композиция” | Яшел түгәрәк кәгазь D15см, кипкән чәчәк таҗлары, агач яфраклары, кләй ПВА, пумала, салфетка. | Иҗади сәләт үстерү; кипкән яфраклар белән эшләргә өйрәтү; кәефләрен күтәрү; үзең ясаган матурлыкка соклану хисе тәрбияләү. |
| **Декабрь** | | | |
| **I атна : «Минем туган илем»** | | | |
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br>Сөйләм теле | «Минем туган җирем» | Слайдлар, фотосурәтләр, хат, аудиоязма, тугра.<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 143 бит.) | 1. Туган шәһәребезгә (авылыбызга) карата горурлык хисе тәрбияләү.<br>2. Үстерелешле диалог, сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.<br>3. Балаларның Ватаныбыз, республикабыз (шәһәр һәм авыл) һәм аның символикасы турындагы мәгълүматларын арттыру.<br>Сүзлек: хат, тугра. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Танып белү үсеше<br><br>Танып белү һәм эзләнү | Әңгәмә. “Чал тарихлы Казаным” | Казанның тарихи урыннары турында слайдларда, фотосурәтләр, казан, тугра, байрак, аудиоязмада Татарстан Республикасы гимны.<br><br>(К.В. Закирова “ Балачак аланы”, 290 бит.) | 1. Балаларда тарихи узаң, башкалабыз Казан турында күбрәк белергә теләк тәрбияләү.<br><br>Сүзлек: Ител. Ачыргаланып, риваять, Казан, тугра, байрак, барс, манара, мәчет. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [д] авазын өйрәнүне дәвам итү | “Тырыш тел” уены,<br><br>[д] авазы кергән исемнәр<br><br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 40 бит) | [н] авазын әйткәндә сөйләм апараты органнарының кирәкле хәрәкәтләрен һәм торышын билгеләү. Авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү. |
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Матур әдәбият белән таныштыру | Шигырь уку: Ә.Синегулов. “Татарстан җирләре”. | Матур әдәбият: К.В.Закирова. «Балачак аланы», 374 бит. | 1. Туган ил, туган йортны ярату, аның белән горурлану хисләре тәрбияләү.<br><br>2. Балаларның фикерләү сәләтен, диалогик сөйләм телен үстерү.<br><br>3. Әсәрнең төп идеясен аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирә белергә өйрәтү.<br><br>Сүзлек: фонтан, дәрья, приказ, указ, көпшәк. |
| Танып белү үсеше<br><br>ЭМКФ | «Геометрик фигуралар» | Мисаллар чишү өчен карточкалар, уен: «Чылбырны чиш” геометрик фигуралар.<br><br>(Перспектив план Е. А Мартынов, И.М. Сучков 31 бит.) | Балаларның геометрик формалар турындагы белемнәрен ныгыту (түгәрәк, куб, цилиндр, конус). 10 санына кадәр мисалларны чишәргә өйрәтүне дәвам итү<br><br>( +1- -1), «янында», «тирәсендә», «арасында» сүзләрен кулланып тирә-юньдә ориентлаша белергә өйрәтүне дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | «Дьенеш блоклары" Х.Кюизенер таякчыклары». | Туп, Уен: "Үз гаражыңны тап", табышмаклар<br>(Перспектив план Е. А Мартынов, И.М. Сучков 32 бит.) | Символиклы тамгалар һәм билгеләр ярдәмендә предметлар турында гы белешмәләрне саннар һәм хәрефләр ярдәмендә күрсәтә белергә өйрәтүне дәвам итү. 8 санының составын 2 шәрләп төзи белергә; саннарның "күршесен" белергә өйрәтү; Тәртип белән санауны ныгыту. Логик уйлауны һәм күзаллауны булдыру. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | "Безнең шәһәрнең - йортлары" | Төсле һәм гади карандашлар, йортлар төшерелгән открыткалар һәм рәсемнәр, альбом бите<br>(Т.М.Бондаренко 450 бит) | Балаларга «архитектура», «фасад» сүзләренең мәгънәсен аңлату. Бер йортның, икенчесеннән кайсы ягы белән аерылып торганын ачыклау. Мөстәкыйль рәвештә төрле йортлар төзергә кызыксындыру уяту.<br>Сүзлек өст. эш: йорт, фасад, архитектура |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | осталарының эшләре! | гжель бизәкле савыт-сабалар, , фломастерлар (зәңгәр һәм зәңгәрсу).<br>(Т.М.Бондаренко 483 бит) | Гжель бизәгенең элементларын өйрәтү; пумаланың бөтен өлеше һәм очы белән рәсем ясауны ныгыту. |
| Эстетик сәнгать үсеше Әвәләү. | «Хайваннар » | Пластилин, такта, таякчык, салфетка | Төрле әвәләү ысулларын кулланып хайваннар әвәләү осталыкларын ныгыту, аларга гына хас булган характерлы билгеләрен күрсәтә белергә өйрәтү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Кошлар» | Клэй, пластилин, без, пумала, гөлҗимеш җимешләре, өрәңге канатчыклары, таякчыклар, күркә савытлары.<br>(Гульянс) | Бер темага үзара бергәләшеп сөйләшеп эшләргә, без белән эш итәргә, күмәкләшеп, дус тату эшләргә өйрәтүне дәвам итү. |
| Танып - белү үсеше Төзү | «Иректе» | Төзелеш материаллар.<br>Л.В.Кусакова | Үзләре уйлап төзү өчен кирәкле материаллар сайлап алырга; төзелеш нең бер эзлелектә булырга тиешлеген аңлату. |
| **Декабрь** | | | |

| II атна: «Кышкы урам» | | | |
|---|---|---|---|
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br>Сөйләм теле | Иҗади хикәя төзү “Кышкы уеннар” | Парлы рәсемнәр, туп<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 192 бит) | Эшчәнлектә үзара дустанә мөнәсәбәт җәрбияләү, тыңлый белү күнекмәләрен камилләштерү.<br>Балаларның таныш булган вакыйгалар турында тулы җөмләләр белән сөйли белү күнекмәләрен үстерү.<br>Бирелгән сораулар аша диалогик сөйләм формаларын камилләштерү.<br>Сүзлек: җепшек, каравыл. кәшәкә. |
| Танып белү үсеше<br>Танып белү һәм эзләнү | Паркка экскурсия. “Килеп җитте матур кыш”. | Чаналар, җимлек, җим, “Буран” мотоциклы рәсеме.<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 186 бит) | 1. Балаларда кызыксыну уяту, табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Чагыштырып тасвирлый белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның кыш, кар үзенчәлекләре турында белемнәрен баету. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [с] авазын сүзләрдә, сөйләмдә дөрес кулланырга күнектерү | Рәсемнәр, шигырьләр, табышмаклар. “ Тишек шар”, “Бәби үстерү” уены.<br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 44 бит) | [с] авазын әйткәндә сөйләм апараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү, логик һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү; интонация, темп, тавыш көче өстендә эшләү; игътибарлылык тәрбияләү, |
| Сөйләм теле үсеше | Хикәя уку: К.Ушинский. | Матур әдәбият: Ф.Ю.Юсупов. «Балалар бакчасы», 314 бит. | 1. Серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Матур әдәбият белән таныштыру | “Кыш әбинең шуклыгы”. | | 2. Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү.<br>3. Кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын ачыклау; балаларны әдәби әсәр аша кышның тасвирланышы белән таныштыру.<br>Сүзлек: өрде, җанвар, корт, шарт-шорт, яра, күшиләр, төпкә. |
| Танып белү үсеше<br>ЭМКФ | “Сәгатьләр”<br>. | Сәгатьләр - (стена, кул, будильник), туп. эш дәфтәрләре.<br>(Т.М.Бондаренко 214 бит) | Балаларны сәгатьләр һәм аны кайда кулланганлыгы белән таныштыру. Саннарны 1 берәмлеккә арттыра һәм киметү белүләрен ныгыту, “өстәрәк”, “астарак”, “түбәндәрәк”, “кадәр”, “өстендә”,” астында” төшенчәләрен куллануны күнектерү. |
| | “Логик бирем” | Таблицада биремнәр, уен: “Сихерле соты” (Т.М.Бондаренко 222 бит) | Бер төркемдәге предметларның бер-берсеннән аерма якларын табырга: Күрсәтмәлеккә нигезләнеп, кушуга һәм алуга гади мәсьәләләр чишү. Шартлы тамгаларны истә калдыру; ай исемнәрен ныгыту. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | “Кыш - үзенең ап-ак келәмен җәйде” | Кәгазъ бите, пумала, краскалар.<br>(Е. А Мартынов, И.М. Сучков 118 бит.) | Салкын гаммалар белән декоратив бизәкләр кулланып кышкы образ ясарга өйрәтү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | «Кышкы пейзаж» | Картиналар, акварель буяу, ак гуашь, пумала, А4 бите.<br>(Т.М.Бондаренко 456 бит) | Тәрәз аша карап кышкы пейзажны ясарга, салкын кышны чагылдырган төсләр сайларга өйрәтү. Балаларда эстетик зәвык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эстетик сәнгать үсеше Кисеп ябыштыру | «Шәһәр урамы» | А4 битләре, төсле кәгазьдән киселгән турыпочмаклар, пумала, кләй, альбом «Безнең шәһәр». | Тирә-юндәге тормышны чагылдырып, кәгазь битендә ябыштырып, катлаулы булмаган композиция төзеп, пөхтә эшләргә өйрәтү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Койрыклы куян» | Карандашлар, күркәләр, ботакчыклар (Бондаренко) | Ботакчык һәм күркәләрдән композиция төзергә өйрәтү. |
| Танып - белү үсеше<br>Төзү | «Кошлар» | Күркәләр, имән чикләвеге, кипкән яфраклар. | Табигый материаллардан кошлар төзергә өйрәтү. |
| **Декабрь**<br>**III атна: «Кыш килде»** | | | |
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br>Сөйләм теле | “Кайда ничек кышлыйлар” | Кыргый хайваннар һәм йорт хайваннары рәсемнәре, кроссворд.<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 195 бит) | 1. Балаларда кыргый хайваннарга карату кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларны кыргый хайваннар, аларның тышкы билгеләре, яшәү рәвешләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>Сүзлек: Букча, сикергән. |
| Танып белү үсеше | “Боз һәм бозлыклар” | Слайдлар, яңа рәсемнәр<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 191 бит) | Балаларда табигать күренешләрен белергә омтылыш, үз фикерен әйтә белү сыйфаты тәрбияләү. Балаларның табигать объектлары белән кызыксынучанлыкларын, диалогик сөйләм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Танып белү һәм эзләнү | | | күнекмәләрен, сүз байлыкларын үстерү. Балаларның табигать турындагы күзаллауларын киңәйтү, әйләнә-тирә чынбарлыкка нәфасәти мөнәсәбәт формалаштыруны дәвам итү.<br>Сүзлек: бозлавык, шугалак, тайгак, тайгаклык, айсберг. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [з] авазын сүзләрдә, сөйләмдә дөрес кулланырга күнектерү | Табышмаклар, шигырьләр, “ Бозлавык”, “Без, без, без идек” уены.<br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 47 бит) | [з] авазын әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү һәм образлы сәләтен үстерү; сәнгатьле сөйләм һәм дикция, интонация өстендә эшләү; игътибарлылык тәрбияләү. |
| Сөйләм теле үсеше<br>Матур әдәбият белән таныштыру | Шигырь ятлау: Г.Латыйп. “Кыш килде”. | Матур тартма, кәгазь кар бөртекләре.<br>(Матур әдәбият: К.В.Закирова. «Балачак аланы», 278 бит.) | 1. Балаларда шигырь юллары аша кышкы табигатькә соклану хисләре, мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. балаларның хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү.<br>3. шигырьнең эчтәлеге буенча куелган сорауларга дөрес җавап алуга ирешү; халык сынамышларына кызыксыну уяту.<br>Сүзлек: мамык, шыгырдый, йомарлаган, саф, йомшак, кырлач, бәс. |
| Танып белү үсеше<br>ЭМКФ | «8 санының составы. Сәгатьләр» | 10 га хәтле саннар; Кюизенера таякчыклары, эш дәфтәре, төсле карандашлар.<br>(Т.М.Бондаренко 238 бит.) | 8 санының ясалышы. Сәгатьләрдә ориентлаша белүне ныгыту. 10 санына хәтле 1гә киметергә һәм арттырырга өйрәтү. Дәфтәр битендә эшләү. Тәрбиячене игътибар белән тыңлап эшчәнлек вакытында үз ялгышларыңны табарга өйрәнү. |
| | «7 һәм 8 саннарының составы» Уен | Уенчыклар, предметлы карточкалар, берничә кисәккә бүленгән квадратлар | Балаларны 7 һәм 8 саннарының 2 санга киметеп ясалышын өйрәтү, “Колумбово яйцо” уены белән таныштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | «Колумбово яйцо» | (Т.М.Бондаренко 254 бит) | Геометрик күзәтүчәнлекне һәм күзаллауны булдыру. Төрле көннәрдән башлап атна көннәрен атау һәм санау күнекмәсен ныгыту. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | "Керпе, керпе балалары белән ылыслыкта" | Керпе һәм керпе балалары төшерелгән сюжетлы картина, альбом бите, гади карандаш.<br>(Т.М.Бондаренко 460 бит) | Предметның пропорцияләрен рәсемдә дөрес чагылдырып, ылыслы агачлар арасында сюжетлы композиция төзергә, рәсемне штрихлый белергә өйрәтү, кызыксынучанлык тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | « Эт баласы». | Цилиндр, эт баласы, гуашь, пумалалар (Т.М.Бондаренко 461 бит) | Цилиндрлы формадан эт баласының мордасын ясау; эмоциональ яктан чагылдыра белергә өйрәтү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Әвәләү. | "Кыш бабай чыршы бәйрәменә ашыга" | Пластилин, такта, таякчык, уенчык кыш бабай.<br>(Т.М.Бондаренко 520 бит.) | Әкият геройларына кызыксыну уяту. Образлы предметларны әвәләргә өйрәтүне дәвам итү. Эстетик караш тәрбияләү.<br>Сүз.эш: итәк, тун, озынча, буй. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Әкияти өй» | Кәгазь һәм картон, кләй ПВА, кайчылар, пумала, салфеткалар.<br>(Л.В.Кусакова) | Күргәзмә буенча үзгәртүләр, өстәмәләр кертеп әкияти өй ясарга өйрәтү. |
| Тан- белү үсеше Төзү | «Куяннарга оя төзү» | Кләй, пумала, квадрат кәгазь битләре (20х20 см) ояга, тасмалар (10х7 см) түбәгә.<br>(Бондаренко 256 бит) | Кәгазь битен берничә квадратка бөкләргә һәм күләмле предмет ясарга өйрәтү. |
| **Декабрь** | | | |

| IV атна: «Яңа ел» | | | |
|---|---|---|---|
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br>Сөйләм теле | Рәсем буенча хикәя төзү.<br>“Кыш. Тиеннәр” | “Кыш. Тиеннәр” рәсеме, җәнлекләр яраткан азык муляжлары, койрыклар гына төшерелгән рәсемнәр.<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 197 бит) | 1. Хайваннарны кызгану, алар турында кайгыртучанлык хисләре уяту.<br>2. Эвристик (уйлап табуга юнәлтелгән) фикер йөртү алымнарын үстерү.<br>3. Балаларның урман җәнлекләре, яшәү рәвешләре турындагы белемнәрен баету, рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү.<br>Сүзлек: яңгырата, соры, җитез. койрык. |
| Танып белү үсеше<br>Танып белү һәм эзләнү | Язма сөйләм “Кыш бабайга хат” | Аудиоязмада “Бу - Кыш бабай” җыры ( Җ. Тәрҗеманов сүзләре, С.Сабиров көе) конверт, каләм, кәгазь)<br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 194 бит.) | 1. Балаларда бәйрәмнәргә карата уңай мөнәсәбәт, үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга җиткерә белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле сөйләм телен , иҗади күзаллауларын үстерү. 3. 3. Балаларда хат яза белү күнекмәләрен, үз тәҗрибәсеннән чыгып бәйрәм турында әйтә алу мөмкинлекләрен камилләштерү.<br>Сүзлек: эри, юлдаш, гөр килә, иңенә салып. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [ч] авазын өйрәнү | Шигырьләр, “Тепловоз” уены, “Чебиләр ашатканда”, “Тел ачтырганда”, “Чыпчык, чык!” уены, тизәйткеч.<br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 48 бит) | [ч] авазын әйткәндә сөйләм апараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү; бу авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү; фонематик ишетү һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү; тавыш көче һәм дикция өстендә эшләү; игътибарлылык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сөйләм теле үсеше<br>Матур әдәбият белән таныштыру | Шигырь ятлау: Д.Гарифуллин “Песнәк”. | Песнәк рәсеме.<br>(Матур әдәбият: К.В.Закирова. « Балачак аланы », 64 бит.) | 1. Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.<br>2. Шигырьне ятлау теләге булдыру, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Балаларда шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре булдыру.<br>Сүзлек: кырау, кырпак, читлек, алъяпкыч. |
| Танып белү үсеше<br>ЭМКФ | «20 эчендә микъдар саны белән танышу» | 20 санына кадәр саннар, уенчыклар, “Серле капчык”, геометрик формалар (шар, куб, цилиндр), таякчыклар, эш дәфтәре, ручкалар. (Т.М.Бондаренко 284 бит | 20 эчендә микъдар саны белщн таныштыру; 20 эчендә тәртип буенча санарга өйрәтүне дәвам итү; 10 саны эчендә биремнәр чишү. Геометрик формаларны истә калдыру. |
| | «8 санының ясалышы»; зур, кечкенә, тигез тамгалары. | Туп, бүлмә гөлләре, уен «Колумбово яйцо», Кюизнер таякчыклары, эш дәфтәрләре, ручкалар.<br>(Т.М.Бондаренко 254 бит.) | 8 саны эчендә микъдар санын өйрәтүне дәвам итү; тәртип буенча һүм кирегә санауны ныгыту; “зур”, “кечкенә”, “тигез” – төшенчәләрен ныгыту. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | “Эх! Күңелледә соң чыршы бәйрәме!” | Пумала, гуашь, ак альбом бите. | Сюжетлы композиция төзеп бәйрәм вакытын рәсемгә төшерергә өйрәтү. Балаларда эстетик күзәтүчәнлек тәрбияләү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Рәсем | “Раштуа төне” | Тонык кәгазьләр, төсле гуашлар.<br>(Е. А Мартынов, И.М. Сучков 119 бит) | Караңгы төсләр кулланып, төнге урамны рәсемдә ясарга өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эстетик сәнгать үсеше Кисеп ябыштыру | “Кар бөртекләре” | Ак кәгазь, пумала, клэй, кайчы. | Балаларны берничә өлештән торган кәгазьдән кар бөртекләре кисәргә өйрәтү. |
| Эстетик сәнгать үсеше Кул эше | «Кышкы агачлар» | Альбом бите , бөгәрләнгән кәгазь бите, кайчылар, клэй, пумала, салфетка. | Кышкы тынычлыкны тоеп, бөгәрләнгән кәгазъ бите белән эшләргә һәм өстәмә карлар, кошлар һ.б.өстәргә өйрәтү. |
| Танып - белү үсеше<br>Төзү | «Көлкәйнең туфлие» | Уен «Квадрат Воскобович» | Әзер схемалы рәсемгә карап квадрат ярдәмендә туфли төзергә өйрәнү. |
| **Январь** | | | |
| **I атна: «Кышлаучы кошлар»** | | | |
| **Бүлек** | **Тема** | **Җиһазларлар** | **Бурычлар** |
| Сөйләм теле үсеше<br>Сөйләм теле | “Кошларга ярдәм итик” | Җимлек, кышлаучы кошлар рәсеме, кошларның битлекләре, төрле тартмалар. (Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 201 бит) | 1. Балаларда кошларга карата сак караш, кайгыртучанлык сыйфатын тәрбияләү.<br>2. уйлап табуга юнәлтелгән фикер йөртү сәләтен үстерү.<br>3. кошларга кешеләрнең ярдәме бик әһәмиятле булуын аңлату.<br>Сүзлек: зәһәр, саклау, куышлы агач, өшетә, зирәк, күгелҗем. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Танып - белү үсеше<br><br>Танып белү һәм эзләнү | “Безнең канатлы дусларыбыз” | Кош тавышлары язылган аудиоязма, кош рәсемнәре.<br><br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 198 бит) | 1. Балаларда кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисе тәрбияләү, аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү.<br><br>2. тышкы билгеләренә ( төсе, зурлыгы), үз-үзләрен тотышларына, тавышларына карап, кышлаучы һәм күчмә кошларны аерып күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү.<br><br>3. Балаларның кышлаучы кошлар турындагы белемнәрен ныгыту.<br><br>Сүзлек: сыртлы, күгелҗем. |
| Сөйләм теле үсеше Авазларны өйрәтү | [ч] авазын сүзләрдә, сөйләмдә дөрес куллану. | Тел ачтыргыч, уен “Чыпчык, чык!” шигырь, тизәйткеч.<br><br>(Иң татлы тел –туган тел М.Ф.Кашапова 49 бит) | [ч] авазын әйткәндә сөйләм апараты органнарының кирәкле хәрәкәтләрен һәм торышын билгеләү; авазны аерым килеш һәм сүзләрдә дөрес әйтергә өйрәтү. |
| Сөйләм теле үсеше<br><br>Матур әдәбият белән таныштыру | Калмык халык әкиятен уку: “ Күңелле чыпчык белән күңелсез карга” | Кошларның койрыгы ясалган рәсемнәр, кошлар битлекләре.<br><br>(Туган телдә сөйләшәбез З.М.Зарипова 202 бит) | 1. Әкиятнең эчтәлегенә төшенергә булышу, матур әдәбият геройлары аша төрле сыйфатларга карата мөнәсәбәт тәрбияләү.<br><br>2. Күрсәтмә образлы, фикерләү сәләтен 1әм узара аралаша белү күнекмәләрен үстерү.<br><br>3. Балаларны әкият эчтәләге буенча сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтү, кошлар турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү.<br><br>Сүзлек: пырхылдап, күңел, көнче, төшенкелек, көенеч, чал, чук, читлек, тәкәббер, чырае, сытылган |

| | | | |
|---|---|---|---|
